Казан шәһәре Думасының

2026 елның 30 гыйнварындагы

2-5 номерлы карары

**Казан шәһәре Думасының**
**2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы**
**«Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен**
**проектлаштыруның җирле нормативлары турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы «Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2017 елның 21 июнендәге 6-17 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 15-30 номерлы, 2020 елның 16 июнендәге 20-40 номерлы, 2021 елның 5 февралендәге 3-4 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 10-18 номерлы, 2024 елның 28 февралендәге 8-28 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларына, әлеге карар кушымтасына нигезләнеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2026 елның 30 гыйнварындагы
2-5 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 4 «Территорияне фуннкциональ-планлаштыру ягыннан оештыру» бүлегендә:

1.1. 4.2 «Торак территорияләрне һәм торак төзелеше кишәрлекләрен планлаштыру ягыннан оештыру» бүлегендә:

1.1.1. сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«- II дәрәҗәле планлаштыру берәмлеге – торак микрорайон (алга таба – торак микрорайон) – торак зоналарының иң эре, эре һәм зур шәһәр торак пунктларындагы гомумшәһәр һәм район әһәмиятендәге магистраль шәһәр юллары, магистраль урамнар, район әһәмиятендәге магистраль юллар, урта һәм кечкенә шәһәр торак пунктларында гомумшәһәр һәм район әһәмиятендәге шәһәр юллары, урамнары белән бүленмәгән, бер яки берничә кварталдан торган, үз чикләрендә көндәлек һәм периодик рәвештә, 5.1.2 таблицасына туры китереп, тиешле объектлар һәм микрорайон әһәмиятендәге яшелләндерелгән территорияләр ярдәмендә халыкка хезмәт күрсәтү булырылган планлаштыру структурасы элементы»;

1.1.2. тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«- III дәрәҗәле планлаштыру берәмлеге – торак квартал (алга таба – торак квартал) – кызыл линияләр чикләрендә, табигать объектларының табигый чикләрендә һәм башка чикләрдә торак төзелешен рөхсәт итә торган функциональ зоналарның планлаштыру структурасы элементы»;

1.1.3. унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Булган төзелеш районнарында, микрорайоннарында торак кварталның зурлыклары нормага салынмый һәм булган планлаштыру структурасыннан чыгып билгеләнә»;

1.1.4. 4.2.1.1 «I һәм II дәрәҗәле (торак районнар һәм микрорайоннар) планлаштыру берәмлекләрен оештыру» пунктчасында:

1.1.4.1. уникенче абзацта «, шул исәптән этләрне йөртү өчен мәйданчыклар. Этләрне йөртү һәм күнегүләр ясау өчен мәйданчыкларны шәһәр

һәм район әһәмиятендәге паркларда урнаштырырга кирәк. Этләрне йөртү өчен мәйданчыкларның зурлыгы кимендә 400-600 кв. м булырга тиеш, булган төзелеш шартларында мәйдан, гамәлдәге территориаль мөмкинлекләрдән чыгып, киметелергә мөмкин» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.4.2. уникенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- 5.1.8.5 пунктчасы нигезендә этләрне йөртү өчен урыннар, этләрне уйнату һәм аларга күнекмәләр өйрәтү мәйданчыклары»;

1.1.4.3. унсигезенче абзацка «, тиешле нигезләр буенча башка урнаштыру варианты булмаган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.1.5. 4.2.1.2 «III дәрәҗәле планлаштыру берәмлекләрен оештыру» пунктчасына дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- 5.1.8.5 пунктча нигезендә этләрне йөртү урыннары һәм этләрне йөртү урыны мәйданы»;

1.1.6. 4.2.1.3 «IV дәрәҗәле планлаштыру берәмлекләрен (күпфатирлы торак йортның җир кишәрлеген) оештыру» пунктчасында:

1.1.6.1. уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Торак кварталның әлеге кварталдагы торак йортларда яшәү өчен кирәкле инженерлык инфраструктурасы объектларын, аларның сак зоналарын исәпкә алып һәм инженерлык коммуникацияләренең техник коридорларын исәпкә алып, аларга транспортта килү юлын тәэмин итеп урнаштырырга кирәк»;

1.1.6.2. 4.2.1.3.4 таблицасын искәрмәләре белән түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.2.1.3.4 таблица

**Торак төзелешендәге торак фонд тыгызлыгын (фатирларның гомуми мәйданын) исәпләү**

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Бинаның җир өстендәге катлары саны | Торак фонд тыгызлгының максималь күрсәткечләре, мең кв. м/га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2.1.1. | Катлар саны аз булган күпфатирлы торак төзелеше | 3 | 10,4 |
| | | | 4 | 12,0 |
| 2 | 2.5 | Катлар саны уртача булган торак төзелеше | 5 | 13,2 |
| | | | 6 | 14,2 |
| | | | 7 | 15,0 |
| | | | 8 | 15,6 |
| 3 | 2.6 | Катлар саны күп булган | 9 | 16,1 |

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Бинаның җир өстендәге катлары саны | Торак фонд тыгызлгының максималь күрсәткечләре, мең кв. м/га |
|---|---|---|---|---|
| | | торак төзелеше (биек йортлар) | 10 | 16,6 |
| | | | 11 | 17,0 |
| | | | 12 | 17,3 |
| | | | 13 | 17,6 |
| | | | 14 | 17,9 |
| | | | 15 | 18,1 |
| | | | 16 | 18,3 |
| | | | 17 | 18,5 |
| | | | 18 | 18,7 |
| | | | 19 | 18,9 |
| | | | 20 | 19,0 |
| | | | 21 | 19,1 |
| | | | 22 | 19,3 |
| | | | 23 | 19,4 |
| | | | 24 | 19,5 |
| | | | 25 һәм аннан күбрәк | 19,6 |

Искәрмәләр:

1. Катлар саны төрле булган һәм берничә рөхсәт ителгән файдалану төре кулланылган очракта, әлеге тыгызлык торак йортларның уртача булган катлар саныннан чыгып исәпләнә (тышкы стеналар габаритларында торак йортларның җир өстендәге катлары буенча гомуми мәйданының торак йортлар төзелеше мәйданына нисбәте).

2. Күпфатирлы йортлар төзегәндә, машина урыннары саны параметрына таләпләрне үтәү шарты белән таблицада китерелгән төзелеш тыгызлыгын түбәндәге очракларда арттырырга рөхсәт ителә, әмма 20 процентттан арттмаска тиеш:

- үзгәртеп оештырыла торган территориядә;
- намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнарның – күпфатирлы йортларны өлешкә кереп төзүдә катнашучыларның хокукларын яклау эшчәнлеге кысаларында күпфатирлы йортлар төзегәндә;
- метрополитен станцияләреннән 500 метрлык радиуста яки җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта.

Берничә шартлар туры килгәндә, тыгызлыкның гомуми арту дәрәҗәсе кушылмый һәм 20 процентттан артмаска тиеш.

3. Күпфатирлы торак йорт (йортлар) файдалана торган түбәле стилобатта (түбәдә яшеллек, балалар уен мәйданчыгы, өлкәннәр өчен ял итү мәйданчыгы, физик культура белән шөгыльләнү мәйданчыгы урнашырга мөмкин) урнаштырылган очракта, стилобат өлешен исәпкә алып, йортның (йортларның) уртача катлар саны стилобатның катлар буенча суммар мәйданының, тышкы стена габаритларында торак йортның (торак йортларның) җир өсте өлешенең торак йортлардагы стилобат дәрәҗәсендәге төзелеш мәйданына нисбәте буларак билгеләнә. Уртача катлар саны бөтен санда булмаганда, торак төзелеш тыгызлыгының максималь күрсәткече линияле интерполяция ысулы белән исәпләнә.

4. Фатирларның гомуми мәйданы күрсәткечләре буенча рөхсәт ителгән төгәлсезлек 1% булырга мөмкин»;

1.1.7. 4.2.3 пунктының 4.2.3.1 таблицасында:

1.1.7.1. «21» санын «18» санына алмаштырырга;

1.1.7.2. «43» санын «35» санына алмаштырырга;

1.2. 4.7 «Табигать-рекреация комплексы» бүлегендәге 4.7.3.2 «Торак функциональ-планлаштыру берәмлекләре составында яшелләндерелгән территорияләрне һәм яшел үсентеләрне урнаштыруның исәпләү күрсәткечләре һәм аларга карата таләпләр» пунктчасында бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- 5.1.8.5 пунктчасы нигезендә этләрне йөртү өчен урыннар, уеннар уйнау һәм аларга күнекмәләр өйрәтү мәйданчыклары»;

2. 5 «Төп өлеш. Җирле әһәмияттәге объектларның һәм шәһәр төзелешендә нормалаштырылган башка объектларның исәпләү күрсәткечләре» бүлегендә:

2.1. 5.1 «Социаль инфраструктура объектларының исәпләү күрсәткечләре» бүлегендә:

2.1.1. өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- уңайлы яшәү һәм халык өчен уңайлы мохит булдыру өчен кирәкле гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр (парклар, скверлар, бакчалар, бульварлар)»;

2.1.2. унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Кертеп, кушып һәм кертеп-кушып төзелгән биналарда урнашкан (проектлана торган) китапханәләр, яшүсмерләр клублары, эчке хокук тәртибен тәэмин итү объектлары (тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары), поликлиникалар, Татарстан Республикасы муниципаль яисә дәүләт милкендәге яисә мондый милеккә тапшыру өчен билгеләнгән биналарда урнашкан (проектланган) очракта, тәэмин ителеш исәбенә кертеләләр»;

2.1.3. 5.1.1 «Укыту-тәрбия бирү билгеләнешендәге объектлар» пунктында:

2.1.3.1. 5.1.1.1.1 таблицасында:

2.1.3.1.1. икенче юлда:

2.1.3.1.1.1. «27» санын «24» санына алмаштырырга;

2.1.3.1.1.2. «57» санын «47» санына алмаштырырга;

2.1.3.1.2. өченче юлдагы 2 һәм 3 баганаларында «25 процентка» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1.3.1.3. җиденче юлны гамәлдән чыккан дип танырга;

2.1.3.1.4. тугызынчы юлның икенче баганасындагы текстны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Мәктәпкәчә һәм мәктәптә белем бирү оешмалары объектлары территориясендә шушы объектларга, шулай ук чиктәш территорияләрдә урнашкан шул ук билгеләнештәге объектларга хезмәт күрсәтүгә бәйле булмаган яңа инженерлык инфраструктурасы челтәрләре һәм корылмалары төзү һәм транзит инженерлык коммуникацияләре төзү рөхсәт ителми, моңа яңа инженерлык коммуникацияләре барлыкка килгән коммуникация коридорларында урнашкан очраклар һәм башка трассаны сайлап алу мөмкин булмаган очраклар керми»;

2.1.3.1.5. унынчы юлны гамәлдән чыккан дип танырга;

2.1.3.2. 5.1.1.1.1 таблицасындагы искәрмәләрдә:

2.1.3.2.1. 2 искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Белем бирү оешмаларында шәхси торак төзелеше йортлары, блоклы йортларның шәхси блоклары (йорт биләмәләре) өчен таләп ителә торган урыннар санын исәпләү Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры мәгълүматлары нигезендә түбәндәге күрсәткечләр буенча гамәлгә ашырыла:

- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында 100 йорт биләмәсенә – 23,04 урын;

- гомуми белем бирү оешмаларында 100 йорт биләмәсенә кабул итәргә – 45,12 урын»;

2.1.3.2.2. 3 искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Башлангыч гомуми белем бирү укучылары өчен гомуми белем бирү оешмаларындагы урыннар исәпләү санының 36 процентыннан артмый»;

2.1.3.3. 5.1.1.1.2 таблицасына искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«Искәрмә:

1. Мәктәп-интернатлар территориясендә шушы объектларга, шулай ук чиктәш территорияләрдә урнашкан шул ук билгеләнештәге объектларга хезмәт күрсәтүгә бәйле булмаган яңа инженерлык инфраструктурасы челтәрләре һәм корылмалары төзү һәм транзит инженерлык коммуникацияләре төзү рөхсәт ителми, моңа яңа инженерлык коммуникацияләре барлыкка килгән коммуникация коридорларында урнашкан очраклар һәм башка трассаны сайлап алу мөмкин булмаган очраклар керми.

2. Мәктәп-интернатларның җир кишәрлекләре зурлыгы, оешманың җир кишәрлегенә таләпләр тәэмин ителгән очракта гына, булган төзелеш шартларында киметелә ала»;

2.1.3.4. 5.1.1.2.1 таблицасына икенче искәрмәне төшереп калдырырга;

2.1.4. 5.1.8 «Социаль инфраструктураның башка объектлары» пунктының 5.1.8.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.1.8.5. Этләр өчен инфраструктура

I һәм II дәрәҗәле планлаштыру берәмлекләре өчен этләрне йөртү урыннары һәм уен мәйданчыкларын гомуми кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләрдә түбәндәге исәптән чыгып урнаштыру зарур:

- этләрне йөртү урыны – 5 мең кв.м торакка 1 эт, 1 эткә 4 кв.м;

- уен мәйданчыклары – 20 мең кв.м торакка 1 эт, 1 эткә 8 кв.м;

- этләрне йөртү урыны мәйданы – 6 квадрат метрдан башлана;

- этләр өчен уен мәйданчыклары мәйданы – 200 квадрат метрдан башлана, барлыкка килгән төзелеш шартларында мәйдан булган территория мөмкинлекләреннән чыгып киметелергә мөмкин.

III дәрәҗәле планлаштыру берәмлекләре өчен этләрне йөртү урыннарын гомуми кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләргә түбәндәге исәп буенча урнаштыру зарур:

- этләрне йөртү урыны – 5 мең кв.м торакка 1 эт, 1 эткә 4 кв.м;

- этләр өчен уен мәйданчыклары мәйданы – 6 квадрат метрдан башлап, барлыкка килгән төзелеш шартларында мәйдан булган территория мөмкинлекләреннән чыгып киметелергә мөмкин.

Шәхси торак төзелеше кварталлары өчен этләрне йөртү урыннары һәм уен мәйданчыкларын гомуми кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләрдә түбәндәге исәп буенча урнаштыру зарур:

- этләрне йөртү урыны – 52 йорт хуҗалыгына 1 эт, уен мәйданчыклары – 209 йорт хуҗалыгына 1 эт;

- этләрне йөртү урыны мәйданы – 6 квадрат метрдан башлана;

- этләр өчен уен мәйданчыклары мәйданы – 200 квадрат метрдан башлана, барлыкка килгән төзелеш шартларында мәйдан булган территория мөмкинлекләреннән чыгып киметелергә мөмкин»;

2.2. 5.2 «Транспорт инфраструктурасы объектларының исәпләү күрсәткечләре» бүлегендә:

2.2.1. 5.2.2 «Урам-юл челтәре. Урам-юл челтәре классификациясе» пунктында:

2.2.1.1. беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Яңа төзелә торган территорияләрдә инженерлык челтәрләре аерым техник коридорда, ягъни юлларның (үтү юлларының) автомобиль юлларыннан читтә проектлаштырыла»;

2.2.1.2. җиденче абзацта «тротуарлар, чишелешләр» сүзләреннән соң «, техник инженерлык челтәрләре коридорлары» сүзләрен өстәргә;

2.2.1.3. 5.2.2.2 таблицасындагы 12 юлның 8 баганасында «1,0» санын «1,5» санына алмаштырырга;

2.2.1.4. 5.2.2.2 таблицасына искәрмәләрдә:

2.2.1.4.1. 7 искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«7. Тротуар киңлеге исәпләү буенча билгеләнә, ләкин 5.2.2.2 таблицасының 8 баганасында күрсәтелгән зурлыктан ким булмаска тиеш. Шәхси торак төзелеше зоналарында булган тыгыз төзелеш шартларында тротуар киңлеге 1,0 м булырга мөмкин»;

2.2.1.4.2. 11 искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«11. Катлаулы рельеф шартларында, шулай ук барлыкка килгән төзелеш шартларында, тарихи һәм шәһәр төзелеше ягыннан югары кыйммәткә ия зоналарда магистраль шәһәр урамнарының һәм юлларының, район әһәмиятендәге магистраль урамнарның, җирле әһәмияттәге урамнарның киңлеге кызыл линияләрдә, аркылы профильнең билгеләнгән минималь параметрларын үтәү һәм таләп ителә торган урамның кызыл линияләрендә проектлана торган инженерлык коммуникацияләре җыелмасын салуны тәэмин итү буенча мәҗбүри шартны үтәп, нормативтан кимрәк кабул ителергә мөмкин. Машина йөрү өлеше астында урнашкан, үзгәртеп корылырга яисә реконструкцияләнергә тиешле инженерлык челтәрләрен, башка урнаштыру урыны булмаганда, машина йөрү өлеше астында урнаштыру рөхсәт ителә»;

2.2.2. 5.2.7.3 «Халыкның җиңел автомобильләрен кую өчен объектлар» пунктындагы 5.2.7.3.1 таблицасын искәрмәләре белән түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.2.7.3.1 таблица

**Төрле функциональ билгеләнештә булган, аерым урнашкан объектларга хезмәт күрсәтү өчен кирәкле машина урыннары саны**

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Исәпләү берәмлеге | Исәп берәмлекләре санына 1 машина урыны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2.1 | Шәхси торак төзелеше өчен | Йортка | Кимендә 1 |
| 2 | 2.3 | Блоклы торак төзелеше | Блокка | Кимендә 1 |
| 3 | 2.1.1. | Катлар саны аз булган күпфатирлы торак төзелеше | Фатирның гомуми мәйданы кв. м | 80 (даими саклау өчен) |
| | | | Фатирның гомуми мәйданы кв. м | 560 (вакытлыча кую өчен – килүчеләр өчен) |
| | | | Кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми | 80 |

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Исәпләү берәмлеге | Исәп берәмлекләре санына 1 машина урыны |
|---|---|---|---|---|
| | | | мәйданы кв.м | |
| 4 | 2.5 | Катлар саны уртача булган торак төзелеше | Фатирның гомуми мәйданы кв. м | 80 (даими саклау өчен) |
| | | | Фатирның гомуми мәйданы кв. м | 560 (вакытлыча кую өчен – килүчеләр өчен) |
| | | | Кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми мәйданы кв.м | 80 |
| 5 | 2.6 | Катлар саны күп булган торак төзелеше (биек йортлар) | Фатирның гомуми мәйданы кв. м | 80 (даими саклау өчен) |
| | | | Фатирның гомуми мәйданы кв. м | 560 (вакытлыча кую өчен – килүчеләр өчен) |
| | | | Кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми мәйданы кв.м | 80 |
| 6 | 3.1.1 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 5 |
| 7 | 3.1.2. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 5 |
| 8 | 3.2.1. | Социаль хезмәт күрсәтү йортлары | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 5 |
| 9 | 3.2.2 | Халыкка социаль ярдәм күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 5 |
| 10 | 3.2.3 | Элемтә хезмәте күрсәтү | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 11 | 3.3 | Көнкүреш хезмәте күрсәтү | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 12 | 3.2.4 | Тулай тораклар | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Яшәүчеләр | 10 |
| 13 | 3.4.1. | Амбулатор-хастаханә хезмәте күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер сменага килүчеләр | 50 |
| 14 | 3.4.2 | Стационар медицина хезмәте күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Койка-урын | 10 |
| 15 | 3.4.3. | Махсус билгеләнештәге медицина оешмалары | Эшләүчеләр | 5 |

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Исәпләү берәмлеге | Исәп берәмлекләре санына 1 машина урыны |
|---|---|---|---|---|
| 16 | 3.5.1. | Гомуми белем бирү мәктәпләре. Килүчеләр өчен машина кую урыннары җир кишәрлеге чикләреннән читтә, урам-юл челтәренең кызыл линияләрендә, юлның киңәйгән урыннарында яки махсус билгеләнгән җир кишәрлегендә урнаштырылырга тиеш. Яңа төзелеш өчен генә кулланыла | Эшләүчеләр | 5 |
| 17 | 3.5.2 | Урта һәм югары һөнәри белем | Укытучылар | 4 |
| | | | Студентлар | 20 |
| 18 | 3.5.1. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары. Шәһәр әһәмиятендәге балалар өчен өстәмә белем бирү объектлары. Килүчеләр өчен машина кую урыннары җир кишәрлеге чикләреннән читтә, урам-юл челтәренең кызыл линияләрендә, юлның киңәйгән урыннарында яки махсус билгеләнгән җир кишәрлегендә урнаштырылырга тиеш. Яңа төзелеш өчен генә кулланыла | Эшләүчеләр | 7 |
| 19 | 3.6.1 | Мәдәният-ял объектлары | Бер тапкыр килүчеләр | 6 |
| 20 | 3.6.3 | Цирклар һәм җәнлекләрне асрау урыннары | Бер тапкыр килүчеләр | 10 |

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Исәпләү бермлеге | Исәп берәмлекләре санына 1 машина урыны |
|---|---|---|---|---|
| 21 | 3.7.1 | Дини йолаларны үтәү | Бер тапкыр килүчеләр | 10 |
| 22 | 3.7.2 | Дини идарә һәм белем бирү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 10 |
| 23 | 3.8.1 | Дәүләт идарәсе | Гомуми мәйдан кв. м | 100 |
| 24 | 3.8.2 | Вәкиллек эшчәнлеге | Гомуми мәйдан кв. м | 100 |
| 25 | 3.9.1 | Гидрометеорология һәм аның белән чиктәш өлкәләрдәге эшчәнлекне тәэмин итү | Эшләүчеләр | 5 |
| 26 | 3.10.2 | Хайваннар өчен приютлар | Эшләүчеләр | 5 |
| 27 | 3.9.2 | Фәнни тикшеренүләр үткәрү | Гомуми мәйдан кв. м | 150 |
| 28 | 3.9.3 | Фәнни сынаулар үткәрү | Гомуми мәйдан кв. м | 150 |
| 29 | 3.10.1 | Амбулатор ветеринария хезмәте күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 10 |
| 30 | 4.1 | Эшлекле идарә | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 31 | 4.2 | Сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслар)) | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 32 | 4.3 | Базарлар | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 33 | 4.4 | Кибетләр | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 34 | 4.5 | Банк һәм иминиятләштерү эшчәнлеге | Гомуми мәйдан кв. м (операцияләр башкару залы белән) | 30 |
| | | | Гомуми мәйдан кв. м (операцияләр башкару залыннан башка) | 65 |
| 35 | 4.6 | Җәмәгать туклануы | Утырту урыннары | 7 |
| 36 | 4.7 | Кунакханә хезмәте күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Урыннар | 5 |
| 37 | 4.8.1 | Күңел ачу чаралары, азартлы уеннар үткәрү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 5 |
| 38 | 5.2.1 | Туристлык хезмәте күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Урыннар | 5 |
| 39 | 5.3 | Аучылык һәм балык тоту | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Урыннар | 5 |
| 40 | 4.9.1.1 | Транспорт чараларына ягулык салу | Постлар | 2 |

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Исәпләү берәмлеге | Исәп берәмлекләре санына 1 машина урыны |
|---|---|---|---|---|
| 41 | 4.9.1.3 | Автомобиль юу урыннары | Постлар | 2 |
| 42 | 4.9.1.4 | Автомобильләрне ремонтлау | Постлар | 2 |
| 43 | 4.9.1.2 | Юл ялын тәэмин итү | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 44 | 4.10 | Күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 45 | 5.1.1 | Спорт-тамаша чараларын тәэмин итү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 25 |
| 46 | 5.1.5 | Су спорты | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 25 |
| 47 | 5.5 | Гольф яки атта йөрү өчен кырлар | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Бер тапкыр килүчеләр | 25 |
| 48 | 5.1.7. | Спорт базалары | Эшләүчеләр | 5 |
| 49 | 5.1.2. | Биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү | Бер тапкыр килүчеләр | 25 |
| | | - спорт клублары | | 4 |
| | | - бассейннар, шугалаклар | | 7 |
| | | физкультура-сәламәтләндерү комплекслары | Бер тапкыр килүчеләр | 10 |
| | | - муниципаль балалар физкультура-сәламәтләндерү комплекслары | | |
| | | - башкалар | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| | | - спорт заллары | Гомуми мәйдан кв. м | 50 |
| 50 | 5.4 | Кече үлчәмле суднолар өчен причаллар | Эшләүчеләр | 5 |
| 51 | 6.0 | Җитештерү эшчәнлеге | Ике сменада эшләүчеләр | 8 |
| 52 | 6.2 | Авыр сәнәгать | | |
| 53 | 6.3 | Җиңел сәнәгать | | |
| 54 | 6.3.1 | Фармацевтика сәнәгате | | |
| 55 | 6.3.2. | Фарфор-фаянс сәнәгате | | |
| 56 | 6.3.3 | Электрон сәнәгать | | |
| 57 | 6.3.4 | Зәркән сәнәгате | | |
| 58 | 6.4 | Азык-төлек сәнәгате | | |
| 59 | 6.5 | Нефть химиясе сәнәгате | | |

| № т/б | Код | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Исәпләү берәмлеге | Исәп берәмлекләре санына 1 машина урыны |
|---|---|---|---|---|
| 60 | 6.6 | Төзелеш сәнәгате | | |
| 61 | 6.7 | Энергетика | | |
| 62 | 6.9 | Склад | | |
| 63 | 6.9.1 | Склад мәйданчыклары | | |
| 64 | 6.11 | Целлюлоза-кәгазь сәнәгате | | |
| 65 | 12.2 | Махсус эшчәнлек | | |
| 66 | 6.8 | Элемтә | | |
| 67 | 6.12 | Фәнни-җитештерү эшчәнлеге | | |
| 68 | 7.1.2 | Тимер юл буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга хезмәт күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Пассажирлар | 8 |
| 69 | 7.2.2 | Пассажирлар йөртүгә хезмәт күрсәтү | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Пассажирлар | 8 |
| 70 | 7.3 | Су транспорты | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Килүчеләр | 8 |
| 71 | 7.4 | Һава транспорты | Эшләүчеләр | 5 |
| | | | Килүчеләр | 8 |
| 72 | 8.0 | Оборона һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү | Эшләүчеләр | 5 |
| 73 | 8.1 | Коралды көчләрне тәэмин итү | | |
| 74 | 8.3 | Эчке хокук тәртибен тәэмин итү | | |
| 75 | 8.4 | Җәзаларны үтәтү эшчәнлеген тәэмин итү | | |
| 76 | 9.2.1 | Шифаханә эшчәнлеге | Ял итүчеләр | 18 |
| | | | Эшләүчеләр | |
| 77 | 12.1 | Ритуаль эшчәнлек | Бер тапкыр килүчеләр | 10 |

Искәрмәләр:

1. 5.2.7.3.1 таблицасының 3, 4, 5 пунктлары нигезендә исәпләгәндә, фатирларның гомуми мәйданы күрсәткечләре буенча төгәлсезлек 1% тәшкил итә.

2. Машина урыннары саны проектта күрсәтелгән исәпләү берәмлекләре санын 5.2.7.3.1 таблицасының бишенче баганасы күрсәткеченә бүлү белән билгеләнә. Машина урыннары исәпләү берәмлегенә пропорциональ рәвештә исәпләнә, нәтиҗә зурайту ягына түгәрәкләнә һәм бер машина урыныннан да кимрәк була алмый.

3. Торак булмаган билгеләнештәге объектлар өчен машина урыннары санын исәпләгәндә, баскыч мәйданчыклары, лифт шахталары, файдаланылмый торган чорма

бүлмәләре, файдаланыла торган түбәләр, террасалар һәм автопарковкалар били торган бүлмәләр, әгәр биеклеге 1,8 метрдан артмаса, техник кат мәйданы, шулай ук, гомуми мәйданы объектның гомуми мәйданыннан 5 процентка артмаса, техник бүлмәләр мәйданы бинаның гомуми мәйданына кертелми. Башка очракларда техник катлар һәм техник бүлмәләр өчен машина урыннарын исәпләү 50 кв. метрга бер машина урыны тәшкил итә.

4. Машина урыннары санының параметрлары якында урнашкан объектларга (гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенда урнашкан һәм (яки) мондый юллардан турыдан-туры керү урыннары, йөк төяү-бушату мәйданчыклары яки җайланмалары булган объектлардан тыш, кварталда яшәүчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән, җәяү йөрерлек радиуста квартал эчкендәге торак төзелешендә урнаштырыла торган, торак йортка кертеп (кушып) төзелгән яисә аерым торган, объектның гомуми мәйданы буенча чикләүләре булган (спорт объектлары өчен – 300 кв.м, башкалары өчен – 150 кв.м) кибетләр, көнкүреш хезмәте күрсәтү, эчке хокук тәртибен тәэмин итү (җәмәгать тәртибен саклау пунктлары), спорт объектларына), капиталь төзелеш объектларының параметрларын үзгәртүгә китерми торган гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә кагылмый.

5. Төрле функциональ билгеләнештәге биналары булган объектлар (күпфункцияле комплекс) өчен һәр бинага, аның функциональ билгеләнешеннән чыгып, аерым исәпләнә. 3 пунктта күрсәтелгәннәрдән кала, гомуми биналар буенча исәп гомуми мәйданның 50 кв.метрына бер машина урыны урнаштырудан чыгып башкарыла.

6. Утырту урыннары саны кунакханәдә яшәү урыннары санынннан артып китә торган, җәмәгать туклануы предприятиеләре (рестораннар, кафелар һ.б.) булган кунакханәләр өчен машина урыннары санын исәпләү кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре өчен аерым башкарыла.

7. Җәяү барып җитәргә мөмкин булган объектларны, мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен, китапханәләрне, яшүсмерләр клубларын, эчке хокук тәртибен тәэмин итү объектларын (җәмәгать тәртибен саклау пунктлары), поликлиникаларны урнаштыру өчен билгеләнгән урыннардан кала, күпфатирлы йортларның кертеп, кушып һәм кертеп-кушып төзелгән бүлмәләрендәге объектлар хезмәткәрләре һәм объектларга килүчеләр өчен кирәкле машина урыннары әлеге биналарның гомуми мәйданының 80 квадрат метрына бер машина урынын тәшкил итә.

8. Җир кишәрлеге чикләрендә урнаштырылырга тиешле машина урыннары санын исәпләүне инвалидларның һәм халыкның хәрәкәтләнү мөмкинлеге чикле төркемнәренең хокукларын тәэмин итү таләпләрен үтәп башкарырга кирәк.

9. Автотранспортны даими саклау өчен машина урынының исәпләнгән саны торак төзелеше түбәндәге территорияләрдә барган очракта 20 процентка кими:

- сәнәгать, җитештерүе, коммуналь-склад территорияләре, транспорт объектлары территорияләре, сәүдә-күргәзмә комплекслары, мәдәни мирас объектларын заманча файдалануга җайлаштыруга бәйле территорияләр урынында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектлары белән тәэмин ителгән торак төзелешен гамәлгә ашыру максатыннан территориянең функциональ билгеләнеше үзгәрү шартларында территорияне үзгәртеп коруны, үзгәртеп оештыруны, адаптив файдалануны, шулай ук гамәлдәге торак фондын реновацияләү буенча чаралар комплексын, ягъни авария хәлендәге,

тузган һәм саклanyрга тиеш булмаган башка торак йортларны җимереп, яңа торак төзүне күздә тоткан үзгәртеп корыла торган территориядә (алга таба – үзгәртеп корыла торган территория);

- метрополитен станцияләреннән алып 500 м радиуста яки җәяү бару мөмкин булган 800 м ераклыкта.

Берничә шарт туры килгәндә, машина урыны процентының гомуми кимүе гомумиләштерелми һәм 20 проценттан артмаска тиеш.

10. Торак булмаган объектлар өчен машина урыннарының исәпләнә торган саны, объект метрополитен станцияләреннән 500 м радиуста яки җәяү барып җитү мөмкинлеге булган 800 м ераклыкта урнашкан очракта, 20 процентка кими.

11. Территорияне комплекслы төзегәндә, машинаны даими саклау урыннарының исәпләнә торган саны расланган проект нигезендә, җәяү барып җитү мөмкин булган 500 метрдан артмаган ераклыктагы, аерым җир кишәрлегендә урнашкан ачык парковкаларда, паркингларда һәм гараж-машина кую объектларында урнаштырыла.

12. 11 пунктта каралмаган очракта, машинаны даими саклау урыннарының исәп санын җәяү барып җитү мөмкин булган 500 метрдан артмаган ераклыктагы, аерым җир кишәрлегендә урнашкан ачык парковкаларда, паркингларда һәм гараж-машина кую объектларында урнаштыру чик параметрлардан чыгуга рөхсәт алу тәртибендә башкарыла.

13. Эшлекле идарә, кунакханә хезмәте күрсәтү файдалану төрләренә бәйле машина урыннары машина урыннарының гомуми исәбенә кертелә. Башка билгеләнештәге биналар һәм бүлмәләр өчен бәйле машина урыннары таләп ителә торган машина урыннарының гомуми исәбенә 0,7 коэффициенты белән кертелә.

Бердән артмаган автомобиль белән блокланган очракта, машина урыннары исәбенә бәйле машина урыннары керә.

14. Җир кишәрлеге чикләрендә гамәлдәге капиталь төзелеш объектлары булган капиталь төзелеш объектын проектлаганда, машина урынын исәпләү, аларның функциональ билгеләнешенә карап, һәр объект өчен таләп ителгән машина урынын исәпкә алып башкарыла.

15. Файдалану төрләре гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары һөнәри белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары булган социаль юнәлештәге федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге объектларны төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм файдалану төрләре амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, стационар медицина хезмәте күрсәтү, махсус билгеләнештәге медицина оешмалары булган объектларны реконструкцияләгәндә, 500 м радиуста яки җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта кирәкле сандагы машина урыннары булдырылган муниципаль парковкалар булган очракта, участок чикләрендә машина урыннарының исәпләнгән санын планлаштырмаска рөхсәт ителә. Шулай ук машина урыннарын урнаштыру өчен бирелгән яисә мондый файдалану мөмкинлеге бирелә торган җир кишәрлекләрендә, шулай ук урам-юл челтәре чикләрендә парковка кесәләре кишәрлекләрендә норматив сандагы машина урыннарын урнаштыру рөхсәт ителә.

16. Социаль юнәлештәге федераль, төбәк һәм муниципаль әһәмияттәге объектларны реконструкцияләгәндә, аларның егәрлеген (килүчеләр, эшләүчеләр, койка урыннары санын) арттыру планлаштырылмаганда, участок чикләрендә яисә янәшәдәге территорияләрдә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, машина урыннарының исәпләнгән санын күздә тотмаска рөхсәт ителә. Шулай ук машина урыннары өчен бирелгән яисә мондый файдалану

мөмкинлеген бирә торган җир кишәрлекләрендә, шулай ук урам-юл челтәре чикләрендәге 500 м радиуста яисә җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта урнашкан парковка кесәләре кишәрлекләрендә кирәкле санда машина урыннары урнаштыру рөхсәт ителә.

17. Файдалану төрләре амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, стационар медицина хезмәте күрсәтү, махсус билгеләнештәге медицина оешмалары булган яңа объектлар төзегәндә, килүчеләр өчен машина кую урыннарын объект кишәрлегендәге биналарга тиешле керү урыннарына кадәр җәяү барып җитәрлек ераклыкта, шулай ук машина урыннары урнаштыру максатыннан бирелгән яисә мондый файдалану мөмкинлеге бирә торган башка җир кишәрлекләрендә күздә тоту рөхсәт ителә. Машина урыннарының норматив саны, 500 м радиуста яки җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта кирәкле санда машина урыннары булган муниципаль парковкалар, шулай ук урам-юл челтәре чикләрендә парковка кесәләре булган очракта, 50 процентка кими.

18. Файдалану төрләре мәдәни-ял итү эшчәнлеге объектлары, спорт базалары, социаль юнәлештәге биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү булган яңа объектлар төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә, килүчеләр өчен машина кую урыннарын объект кишәрлегендәге биналарга тиешле керү урыннарына кадәр җәяү барып җитәрлек ераклыкта, шулай ук машина урыннары урнаштыру максатыннан бирелгән яисә мондый файдалану мөмкинлеге бирә торган башка җир кишәрлекләрендә күздә тоту рөхсәт ителә. Машина урыннарының тиешле саны, 500 м радиуста яки җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта кирәкле санда машина урыннары булган муниципаль парковкалар, шулай ук урам-юл челтәре чикләрендә парковка кесәләре булган очракта, 50 процентка кими.

19. Яңа спорт, социаль юнәлештәге мәдәни-ял итү эшчәнлеге (китапханәләр, мәдәният йортлары) объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә, килүчеләр өчен машина кую урыннарын объект кишәрлегендәге биналарга тиешле керү урыннарына кадәр җәяү барып җитәрлек ераклыкта, шулай ук машина урыннары урнаштыру максатыннан бирелгән яисә мондый файдалану мөмкинлеге бирә торган башка җир кишәрлекләрендә күздә тоту рөхсәт ителә. Машина урыннарының норматив саны, 500 м радиуста яки җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта кирәкле санда машина урыннары булган муниципаль парковкалар, шулай ук урам-юл челтәре чикләрендә парковка кесәләре булган очракта, 50 процентка кимергә мөмкин.

20. Күпфатирлы торак төзелеше өчен машина урыннарының норматив санын, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан чыгуга рөхсәт алып, тиешле санда урыннар булган гамәлдәге муниципаль парковкаларда күздә тоту рөхсәт ителә.

21. Килүчеләр өчен исәпләнгән санда машина урыннары түбәндәге урыннарда урнаштырылырга мөмкин:

- торак йортның җир кишәрлеге өслегендә, шул исәптән киртәләүче корылмалар булмаган стилобат чикләрендә (ачык киңлектә);

- торак йорт стилобатында;

- торак йорт кишәрлегеннән җәяү барып җитәрлек 50 метрдан яки чик параметрлардан тайпылуга бирелгән рөхсәт нигезендә яисә территорияне планлаштыруның мондый проектын нигезләү материаллары төзелеш проекты буенча расланган территорияне планлаштыру проекты нигезендә, куркынычсыз җәяүлеләр юлын оештырып, торак йорттан килүчеләр өчен машина кую урыннарына кадәр җәяү барып җитәрлек 200 метрдан артмаган радиуста урнашкан җир кишәрлеге өслегендә;

- чик параметрлардан тайпылуга бирелгән рөхсәт нигезендә, үзгәртеп корыла торган территорияләрдә һәм тарихи җирлек чикләрендә яисә башка территорияләрдә стилобатта, җир асты яисә җир өсте паркингында.

22. Парклар, скверлар, яр буйлары һәм килүчеләрнең автотранспорттан файдалану мөмкинлеге чикләнгән башка җәмәгать урыннары территорияләрендә урнашкан (җәмәгать урыннарының җәяүлеләр зонасында урнашкан) иҗтимагый билгеләнештәге торак булмаган объектлар өчен җир кишәрлеге чикләрендә машина урыннары урнаштыру таләп ителми.

23. Комплекслы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган территория өчен машина урыннарының исәпләнгән саны, территорияне планлаштыру проектында каралган очракта, муниципаль парковкаларда урнашырга мөмкин.

24. Әгәр әлеге Нормативлар буенча башкасы каралмаган булса, капиталь төзелеш объектларының барлык төрләрен төзү өчен парковка урыннарының норматив санын урнаштыру рөхсәт ителә:

- рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт алу тәртибендә тиешле санда парковка урыннары каралган гамәлдәге муниципаль парковкаларда;

- капиталь төзелеш объектларына норматив сандагы парковка урыннарын урнаштыру өчен территорияне планлаштыруның расланган проектында каралган муниципаль парковкаларда.

25. Тарихи территорияләрдә урнашкан объектлар өчен аерым таләпләр:

- күпфатирлы йортлар өчен автотранспортны даими саклау өчен машина урыннарының исәпләнгән саны, торак булмаган объектлар өчен машина урыннарының исәпләнгән саны 30 процентка киметелә;

- гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын мондый объект параметрларының артуына, әмма 15 процenttан артмаган күләмдә артуна китерә торган итеп реконструкцияләгәндә, автотранспортны даими саклау өчен машина урыннарының исәпләнгән саны билгеләнми;

- бәйле машина урыннары таләп ителә торган машина урыннары санының гомуми исәбенә 1 коэффициенты белән кертелә;

- 500 м радиуста яки җәяү барып җитәрлек 800 м ераклыкта тиешле санда машина урыннары оештырылган муниципаль парковкалар булган очракта, дини билгеләнештәге объектларны реконструкцияләгәндә һәм яңасын төзегәндә, автотранспортны даими саклый торган машина урыннарының исәпләнгән саны билгеләнми;

- 100 м радиуста яисә җәяү барып җитәрлек 200 м ераклыкта тиешле санда машина урыннары оештырылган муниципаль парковкалар булган очракта, гомуми мәйданы 100 кв. метрдан артмаган иҗтимагый төзелеш объектлары һәм гомуми мәйданы 100 кв. метрдан артмаган күпфатирлы йортларның кертеп-кушып төзелгән торак булмаган биналары өчен автотранспортны даими саклауга машина урыннарының исәпләнгән саны билгеләнми;

- килүчеләр өчен машина урыннарының исәпләнгән саны түбәндәге урыннарда урнаштырылырга мөмкин:

1) торак йортның җир кишәрлеге өлекләре, шул исәптән киртәләүче корылмалар булмаган стилобат чикләрендә (ачык киңлектә);

2) торак йорт стилобатында;

3) торак йорт кишәрлегеннән җәяүлеләр өчен 50 метрдан да артмаган радиуста урнашкан җир кишәрлеге өслегендә. Бу очракта – чик параметрлардан тайпылуга рөхсәт алу шарты белән;

4) стилобатта, җир асты яки җир өсте паркингында»;

2.2.3. 5.2.8 «Территорияләр типлары һәм төрләре буенча территориаль яктан һәркем файдалана алырлык дифференциацияләнгән күрсәткечләр» пунктының 5.2.8.1 «Торак территорияләр өчен күрсәткечләр» пунктчасында:

2.2.3.1. җиденче абзацны гамәлдән чыккан дип танырга;

2.2.3.2. 5.2.8.1.1 таблицасын искәрмәләре белән гамәлдән чыккан дип танырга;

2.3. 5.3 бүлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

## «5.3 бүлек. Инженерлык инфраструктурасы объектларының исәпләү күрсәткечләре

5.3.1. Инженерлык инфраструктурасы объектлары классификаторы

Казан шәһәр округы территориясендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектлары түбәндәгеләргә бүленә:

а) федераль әһәмияткә ия – төбәкара һәм система формалаштыручы объектлар;

б) төбәк (республика) әһәмиятендәге объектлар – Казан шәһәр округы һәм Татарстан Республикасының күрше муниципаль районнары халкының һәм территорияләренең уртак тормыш алып баруын тәэмин итү өчен билгеләнгән объектлар;

в) җирле әһәмияттәге – Казан шәһәр округы халкының яшәешен һәм аның тулаем һәм аерым өлешләре территорияләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән инженерлык инфраструктурасы объектлары;

г) шәхси әһәмияткә ия – капиталь төзелешнең аерым объектын тәэмин итү өчен билгеләнгән инженерлык инфраструктурасы объектлары.

Җирле әһәмияттәге объектлар, инженерлык инфраструктурасының шәһәр системаларындагы һәм гамәлдә булган зоналардагы әһәмиятләреннән чыгып, категорияләргә бүленә:

1) тулаем яисә берничә административ районда шәһәр округы халкының һәм территориясенең яшәешен тәэмин итү өчен билгеләнгән шәһәр әһәмиятендәге объектлар;

2) торак район һәм микрорайон халкының яшәешен һәм территориясен,

иҗтимагый-эшлекле һәм җитештерү зонасын, рекреация зонасын тәэмин итү өчен билгеләнгән район әһәмиятендәге объектлар;

3) берничә объектны, комплексны, кварталны тәэмин итү өчен билгеләнгән локаль объектлар.

Инженерлык инфраструктурасы объектлары түбәндәге типларга бүленә: су белән тәэмин итү объектлары; шәһәр агынты суларын, җир өсте агынты суларын һәм дренаж суларын агызу объектлары; җылылык, энергия белән тәэмин итү объектлары; электр белән тәэмин итү объектлары; газ белән тәэмин итү объектлары; элемтә объектлары; коммуникация коллекторлары, кардан чистарту объектлары.

Инженерлык инфраструктурасы объектлары һәр типта линия объектларына һәм корылмаларына бүленәләр.

Су белән тәэмин итү системасының шәһәр әһәмиятендәге объектлары төрләренә – диаметры 900-1200 мм булган суүткәргечләр, су әзерләү станциясе, 1 нче һәм 2 нче күтәрелеш суүткәргеч насос станцияләре булган «Волжский» һәм «Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өслектәге суны җыю корылмалары; тәүлегенә 2000 куб метрдан артык җитештерүчәнлектәге гамәлдәге җир асты су җыю корылмалары, су чистарту станциясе һәм 1 нче, 2 нче һәм 3 нче күтәрелеш суүткәргеч насос станцияләре белән проектлана торган «Столбище» җир асты суын алу корылмасы; район әһәмиятендәге объектлар төрләренә – диаметры 300-600 мм булган суүткәргеч магистральләр, суүткәргеч җайга салу узеллары, суүткәргеч насос станцияләре; җитештерүчәнлеге тәүлегенә 600 куб.метрдан артып, тәүлегенә 2000 куб. метрга кадәр булган җир асты су җыю корылмалары; локаль объектларга диаметры 100-250 мм булган суүткәргеч челтәрләр, җитештерүчәнлеге тәүлегенә 600 куб. метрга кадәр җитә торган җир асты су җыю корылмалары керә.

Шәһәрдәге агынты суларны агызу системасының шәһәр әһәмиятендәге объектлары төрләренә керә: диаметры 800-2000 мм булган канализация каналлары һәм басымлы үткәргеч торбалар; канализациянең биологик чистарту корылмалары; тәүлегенә 50 мең куб. метрдан артык җитештерүчәнлектәге канализация-насос станциясе; 40 мең куб. м һәм аннан да югарырак сыйдырышлы канализация-насос станциясе каршындагы җайга салу резервуарлары; агып төшүче су утырмаларын эшкәртү һәм алга таба утильләштерү (механик рәвештә сусызландыру цехы, депонирлау полигоны, сусызланган явым-төшемнәрне яндыру/компостлаштыру заводы, ләм мәйданчыклары); район әһәмиятендәге объектлар төрләренә – диаметры 400-600 мм булган канализация коллекторлары; җитештерүчәнлеге тәүлегенә 10 мең

куб.метрдан тәүлегенә 50 мең куб. метрга кадәр булган канализация насос станцияләре; канализация насос станцияләре каршында 40 мең куб. метрдан кимрәк булган җайга салу резервуары, егәрлеге тәүлегенә 0,5 мең куб. метрдан 10 мең куб. метрга кадәр булган чистарту корылмалары; локаль объектлар төрләренә – диаметры 100-300 мм булган канализация челтәрләре; егәрлеге тәүлегенә 0,5 мең куб. метрга кадәр булган чистарту корылмалары; егәрлеге тәүлегенә 10 мең куб. метрдан кимрәк булган канализация насос станциясе, локаль (коллектив) септиклар (үзәкләштерелгән канализация системасы барлыкка килгәнче вакытлы объект буларак).

Өслектәге һәм дренаж суларны агызу системасы төрләренә керә: район әһәмиятендәге объектларга – диаметры 400-3500 мм булган су агызу коллекторлары һәм әлеге коллекторларда яңгыр насос станцияләре, 40 гектардан артык су җыю мәйданыннан аккан суны кабул итәргә исәпләнгән һәм өслектәге агынты суны чистарту корылмалары һәм бу чистарту корылмаларындагы җайга салу резервуарлары, җайга сала торган буалар, район әһәмиятендәге чистарту корылмаларыннан чистартылган суны үткәргеч торбалар, җылылык челтәрләре дренажлары, коммуникация коллекторлары; локаль әһәмияткә ия объектларга – диаметры 400-600 мм булган су агызу челтәрләре һәм 40 гектарга кадәр булган су җыю мәйданыннан аккан суны кабул итәргә исәпләнгән чистарту корылмалары.

Электр белән тәэмин итү системасының шәһәр әһәмиятендәге объектлары төрләренә, республика әһәмиятендәге шундый ук егәрлекле объектлардан кала, проект номиналь көчәнеш классы 35 кВ-110 кВ тәшкил иткән электр тапшыру линияләре һәм электр подстанцияләре; электр тапшыру һава линияләренең әлеге электр тапшыру линияләрендәге кабель линияләренә күчү пунктлары; район һәм локаль әһәмияттәге объектларга – проект номиналь көчәнеш классы 6, 10, 20 кВ тәшкил иткән электр тапшыруның туклану һәм бүлү линияләре, бүлү пунктлары, шул исәптән трансформатор подстанцияләре белән берләштерелгәннәре; тоташтыру пунктлары; трансформатор подстанцияләре керә.

Газ белән тәэмин итү системасының шәһәр әһәмиятендәге объектлары төрләренә – диаметры 500-1200 мм булган I категорияле югары басымлы газүткәргечләр; диаметры 500-800 мм булган II категорияле югары басымлы газүткәргечләр; диаметры 400-600 мм булган III категорияле урта басымлы газүткәргечләр, бу газүткәргечләрдә газ чыгымын коммерцияле исәпкә алу узеллары, житештерүчәнлеге 10 мең куб. м/сәг һәм аннан да күбрәк булган газ бүлү пунктлары; район әһәмиятендәге объектлар төрләренә – диаметры 200-400 мм булган II категорияле югары басымлы һәм III категорияле урта басымлы

газүткәргечләр; диаметры 300 мм һәм аннан да күбрәк булган IV категорияле түбән басымлы газүткәргечләр, җитештерүчәнлеге 2 мең куб. м/сәг күбрәк һәм 10 мең куб. м/сәг тән кимрәк булган газ бүлү пункты; локаль объектлар төрләренә диаметры 200 мм дан кимрәк булган III категорияле югары һәм урта басымлы газүткәргечләр; диаметры 300 мм һәм аннан кимрәк булган IV категорияле түбән басымлы газүткәргечләр; җитештерүчәнлеге 2 мең куб. м/сәг кимрәк булган газ бүлү пункты керә.

Элемтә системасының шәһәр әһәмиятендәге объектлары төрләренә – узеллы автомат телефон станцияләре, телефон канализациясендәге 24 һәм аннан да күбрәк тишем сыйдырышлы узелара магистраль һәм тоташтыру кабель линияләре, терәк-көчәйтү станцияләре, кабель телевидениесенең техник үзәге, магистраль фидер линияләре; район әһәмиятендәге объектлар төрләренә – терәк автомат телефон станцияләре, чыбыклы тапшырулар станциясе блогы, кабельле телевидениенең техник үзәге, 612 тишем сыйдырышлы телефон канализациясе, чыбыклы тапшыруларның бүлү фидер линияләре; локаль объектлар төрләренә – автомат телефон станцияләре, абонент цифрлы концентраторы, оптик бүлү шкафлары, 12 тишемгә кадәр сыйдырышлы телефон канализациясе, тавыш трансформатор подстанциясе, чыбыклы тапшыруларның бүлү фидер линияләре, 6 тишемнән кимрәк сыйдырышлы телефон канализациясендәге бүлү кабель линияләре.

Коммуникация коллекторлары объектлары төрләренә түбәндәгеләр керә: төрле төрдәге инженерлык коммуникацияләрен берләштереп салу өчен гомуми коллекторлар, электр тапшыруның кабель линияләрен салу өчен кабель коллекторлары; диспетчерлык пунктлары.

Кар чистарту объектлары төрләренә «коры» кар чүплекләре һәм кар эретү шахталары керә: җылылык чыганагы буларак шәһәрдән агып төшүче суларны кулланып, канализация коллекторында стационар шахталар; җылылык белән тәэмин итү системасының шәһәр челтәрләреннән җылылык энергиясен йөртүче буларак кулланып, җылылык челтәрендә стационар шахталар; тышкы җылылык чыганагы (газ горелкасы, дизель генераторы) яки шәһәр челтәрләренең җылылык энергиясен кулланып җылытылган суны җылылык чыганагы буларак файдаланып, җир өстендәге агынты суны чистарту корылмасында яки елга коллекторында стационар шахталар; кар суын канализация челтәрләренә һәм коллекторларга агызып, дизель яки газ ягулыгында мобиль шахталар.

5.3.2. Территорияне план буенча үстерү параметрларын билгеләгәндә, инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру кагыйдәләре

5.3.2.1. Объектларны, территорияләрне инженерлык-техник тәэмин итү

буенча проект документларын эшләгәндә түбәндәге норматив документларга нигезләнергә:

- 42.13330.2016 номерлы «Кагыйдәләр җыелмасы. Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасы;

- 31.13330.2021 номерлы «Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар» кагыйдәләр җыелмасы;

- 32.13330.2018 номерлы «Канализация. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар» кагыйдәләр җыелмасы;

- 124.13330.2012 номерлы «Җылылык челтәрләре» кагыйдәләр җыелмасы;

- 62.13330.2011* номерлы «Газ бүлү системалары» кагыйдәләр җыелмасы;

- ГОСТ Р 21.101-2020 «Төзелеш өчен проект документлары системасы. Проект һәм эш документларына карата төп таләпләр»;

- 2.2.1/2.1.1.1200-03 номерлы «Санитар-сак зоналары һәм предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитария классификациясе» санитария нормалары һәм кагыйдәләре;

- инженерлык инфраструктурасы челтәрләрен һәм объектларын төзүне җайга салучы башка норматив документлар.

5.3.2.2. Инженерлык инфраструктурасы челтәрләрен һәм корылмаларын проектлаштыруны ресурс белән тәэмин итүче (эксплуатацияләүче) оешмаларның техник шартлары нигезендә һәм аларга таянып алып барырга.

5.3.2.3. Объектларны, территорияләрне инженерлык-техник тәэмин итү буенча проект документлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренә, Казан шәһәр округының Генераль планына, территорияне планлаштыру буенча проект документларына, объектның архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан күренеше составында расланган төзү яки реконструкцияләү планлаштырыла торган объектларның инженерлык коммуникацияләренең җыелма планына (инженерлык коммуникацияләренең аерым/мөстәкыйль трассаларын проектлаганда), инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру концепциясенә каршы килмәскә тиеш.

5.3.2.4. Яңа төзелеш объектларын проектлаштырганда, гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен һәм төзелеш зонасына эләгә торган корылмаларны чыгару/үзгәртеп кору каралырга тиеш.

5.3.2.5. Проектлаштыру башланганга кадәр территориянең агымдагы үзгәрешләрен төшерү эшләрен башкару тәкъдим ителә.

5.3.2.6. Яңа инженерлык коммуникацияләре, 5.3.2.7 пунктта күрсәтелгән очраклардан тыш, җир астына урнаштырылырга тиеш.

Казан шәһәр округының тышкы күренешен яхшырту һәм барлыкка килгән территорияләрне саклап калу һәм комплекслы төзекләндерү зоналарында инженерлык коммуникацияләрен реконструкцияләгәндә яисә территорияләрне комплекслы үзгәртеп корганда тормышны тәэмин итү системаларының куркынычсызлыгын булдыру максатыннан җир өстендәге һәм җир өсте инженерлык коммуникацияләрен җир асты коммуникацияләренә үзгәртеп коруны, шул исәптән көчәнеше 6 кВ һәм аннан артыграк булган һава электр тапшыру линияләрен җир асты кабель линияләренә үзгәртеп коруны күз алдында тотарга кирәк.

Барлык көчәнешле гамәлдәге һава электр тапшыру линияләрен саклап калу һәм аларны реконструкцияләү (капиталь ремонтлау), җитештерү һәм табигать зоналары территорияләрендә, шулай ук табигый һәм ясалма киртәләр (тимер юллар, елгалар, чокырлар һ.б.) белән кисешкәндә, тиешле техник-икътисади һәм экологик нигезләмә булганда гына мөмкин.

5.3.2.7. Җир өстендәге һәм җир өсте линия объектлары, шулай ук җир асты линия объектларының җир өстендәге һәм җир өсте элементлары урнаштырыла:

а) 18.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы таләпләрен исәпкә алып, җитештерү зоналары территориясендә, шулай ук иҗтимагый-эшлекле һәм торак зоналар чикләренә керүче җитештерү объектлары участоклары территориясендә;

б) торак һәм иҗтимагый-эшлекле зоналар территориясендә:

- суүткәргеч һәм җылылык челтәрләре – җир асты инженерлык коммуникацияләре буенча эшләр үткәрү чоры өчен вакытлыча буларак гына;

- җылылык челтәрләрендәге гамәлдәге һәм яңа камералар-павильоннар; җир асты үткәргеч торбаларның газ җиһазы; инженерлык коммуникацияләре өчен коллекторларның вентиляция камералары – торак төзелеше (йортлар, комплекслар, төркемнәр) участоклары территориясеннән, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, гомуми белем бирү һәм медицина оешмалары участоклары территорияләреннән тыш;

- гамәлдәге һәм яңа җир өстендәге газүткәргечләр: биналарның тышкы стеналарында һәм түбәләрендә; торак һәм иҗтимагый-эшлекле зоналарда, шәхси торак төзелеше зоналарында һәм гражданнарның бакчачылык берләшмәләре территориясендә урнаштыру рөхсәт ителә торган, җир астында төзү мөмкинлеге булмау нигезләнгән очракта, газ көйләү пунктына яисә газлаштырылган объектларга (котельныйлар, коммуналь билгеләнештәге объектлар һ. б.) тоташтыру газүткәргечләре; табигый каршылыклар аша (тирән чокырлар, елгалар һ. б.) яки катлаулы гидрогеологик шартларда, 62.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасының 5.3 бүлеге таләпләре үтәлгәндә;

- бина түбәләрендәге махсус баганаларда металл элементлары булмаган чыбыклы тапшыруларның гамәлдәге һава линияләре;

- шәхси торак төзелеше зоналарында һәм гражданнарның бакчачылык берләшмәләре территориясендә, җир астында төзү мөмкинлеге булмау нигезләнгән очракта, булган һава электр тапшыру линияләре баганаларында чыбыклы һава үткәргеч линияләре;

- 0,4 кВ дан артык булмаган көчәнешле гамәлдәге һава электр үткәргеч линияләре;

- шәхси торак төзелешендә, шул исәптән гражданнарның бакчачылык берләшмәләре территориясендә, 0,4 кВдан артык булмаган көчәнешле яңа һава электр үткәргеч линияләре; вакытлыча – объектлар төзелеше чорында табигый каршылыклар (тирән чокырлар, елгалар һ.б.) аша үткәндә.

Гамәлдәге төзелешләрдә, шәхси торак төзелешеннән һәм гражданнарның бакчачылык берләшмәләре территорияләреннән кала, барлык көчәнешле электр тапшыру линияләрен реконструкцияләгәндә, аларны җир асты кабель линияләренә күчерүне күздә тотарга кирәк;

в) Казан шәһәр округының Генераль планында каралган кабель линияләренә үзгәртеп корганчы, гамәлдәге 35-220 кВ көчәнешле электр энергиясен тапшыру һава линияләре.

5.3.2.8. Түбәндә күрсәтелгән объектлар территориясендә, яңа инженерлык коммуникацияләре барлыкка килгән коммуникация коридорларында урнашкан очраклардан һәм башка трасса сайлап алу мөмкин булмаганда, әлеге объектларга хезмәт күрсәтүгә бәйле булмаган яңа инженерлык челтәрләре һәм инфраструктурасы корылмалары төзү рөхсәт ителми:

а) мәктәпкәчә белем бирү һәм белем бирү (гомуми белем бирү һәм махсуслаштырылган) оешмалары, спорт оешмалары һәм спорт буенча массакүләм дәресләр өчен корылмалар, медицина оешмалары участоклары;

б) балаларга уеннар өчен, өлкәннәргә ял итү һәм спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар;

в) махсус билгеләнештәге зоналар: зиратлар, крематорийлар, чүп полигоннары һ.б.

5.3.2.9. 5.3.2.8 пунктында санап үтелгән участоклар территориясендәге гамәлдәге инженерлык корылмалары һәм коммуникацияләре территорияне үзгәртеп кору башланганчы яки инженерлык корылмасын яки коммуникацияне реконструкцияләү башланганчы һәм участок чикләрендә күзәтү коелары булмаган очракта саклана.

Территорияне үзгәртеп оештырганда, 5.3.2.8 пунктта күрсәтелгән

объектларны планлаштырылган урнаштыру зонасыннан транзит инженерлык коммуникацияләрен һәм корылмаларын күчерүне күздә тоту зарур.

5.3.2.10. Казан шәһәре территориясендә түбәндәгеләрне төзү рөхсәт ителми:

а) 500 кВ көчәнешле электр станцияләре һәм электр үткәрү линияләрен;

б) көчәнеше 35-220 кВ булган ачык типтагы электр подстанцияләрен. Гамәлдәге 35-220 кВ һәм аннан югары көчәнешле ачык типтагы электр подстанцияләрендә торак һәм мәдәни-көнкүреш биналарында тавыш дәрәҗәсен норматив дәрәҗәгә кадәр киметүне тәэмин итә торган тавыштан саклау чараларын һәм халыкны электромагнит йогынтысыннан саклау чараларын гамәлгә ашырырга кирәк;

в) Казан шәһәр округының Генераль планында каралган һәм проектлау башланган объектлардан кала, һавада башкарылучы барлык көчәнешләрне электр тапшыруның яңа линияләрен һәм шәхси торак төзелешендә, шул исәптән гражданнарның бакчачылык берләшмәләре территориясендә 0,4 кВ көчәнешле, шулай ук 0,4 кВ көчәнешле вакытлыча (объектларны төзү чорына эшләр тәмамланганчы) электр тапшыру линияләрен; 6 кВ дан артмаган көчәнешле – табигый һәм ясалма каршылыклар (тирән чокырлар, елгалар һ. б.) аша үтү урыннарында;

г) Казан шәһәр округының Генераль планында Казан шәһәр округы чикләреннән чыгару каралмаган, җитештерү объектларының эшләвен тәэмин итә торган корылмалардан һәм үткәргеч торбаларның соңгы участокларыннан кала, магистраль торбаүткәргеч транспортына караган гамәлдәге линия объектлары һәм корылмалары, проектларны этаплап гамәлгә ашырып, муниципаль берәмлек чигеннән чыгарылырга тиеш;

д) торак төзелеше территориясе буенча сәнәгать предприятиеләрен һәм коммуналь-склад объектларын тәэмин итү өчен җиңел янып китүчән һәм янучан сыекчалы, шулай ук сыекландырылган газлы торбаүткәргечләрне.

5.3.2.11. Инженерлык коммуникацияләрен Казан шәһәр округының Генераль планында төзелгән территория буенча урнашкан территорияләрне саклап калу һәм комплекслы төзекләндерү зоналарына кертү, гамәлдәге биналарга һәм корылмаларга, транспорт инфраструктурасы объектларына, башка инженерлык коммуникацияләренә кадәр норматив ераклыкларны үтәүне исәпкә алып, коммуникацияләрнең һәм алардан кулланучыларга тармакларның иң кыска озынлыгын тәэмин итәргә тиеш.

Үсеш һәм үзгәртеп кору зоналарына кертелгән территорияләр буенча инженерлык коммуникацияләре узганда, трассаларны сайлау әлеге

территорияләрнең шәһәр төзелешен проектлау буенча расланган документлар белән билгеләнгән перспективалы планлаштырылуын һәм төзелешен исәпкә алып башкарылырга тиеш.

5.3.2.12. Техник полосалар Казан шәһәр округының Генераль планында, федераль, төбәк һәм муниципаль тармак схемаларында һәм программаларында, коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасында һәм территорияне планлаштыру документларында каралган инженерлык коммуникацияләрен төзү һәм реконструкцияләү чараларын исәпкә алып формалаштырыла.

Перспективалы урам-юл челтәренең аркылы профильләре чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу өчен техник полосаның киңлеге күрше инженерлык челтәрләре арасында 42.13330.2016 номерлы кагыйдәләр җыелмасы, 62.13330.2011 номерлы кагыйдәләр җыелмасы белән билгеләнгән горизонталь буенча (яктылыкта) ераклыкны саклауны; әлеге техник полосада уза торган инженерлык коммуникацияләре җыелмасын һәм характеристикаларын, эшләрне башкару ысулын, салу тирәнлеген, җир астына салу траншеяларында грунт ишелү призмаларын, инженерлык-геологик шартларны исәпкә алып билгеләнә. Инженерлык челтәрләренең, шул исәптән кырый коммуникацияләрнең саклау зоналары техник полоса киңлегенә керә.

Урам-юл челтәре чикләрендәге техник полосаның киңлеге бер яктан үсеш зоналарында шәһәр һәм район әһәмиятендәге яңа инженерлык коммуникацияләрен урнаштыру өчен кызыл линияләрдән, төзелмәгән территорияләрдә һәм, шартлар мөмкинлек бирсә, төзелгән территорияне үзгәртеп кору зоналарында проектлана торган инженерлык коммуникацияләре җыелмасына бәйле һәм кимендә 16 м булырга тиеш. Урам-юл челтәре эчендәге кызыл линияләрдән ике яклап билгеләнә торган техник полосалар киңлеге һәркайсы кимендә 10 метр булырга тиеш.

Яңа районнар төзегәндә һәм, шартлар мөмкинлек бирсә, төзелгән территорияләрне үзгәртеп корганда, микрорайоннар, кварталлар, участоклар территорияләре буенча салынган гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен техник полосалар территориясенә күчерергә тәкъдим ителә. Бу очракта техник полосаның киңлеге аның чикләрендә өстәмә инженерлык коммуникацияләре урнаштыруны исәпкә алып арттырылырга тиеш.

Техник коридорларны формалаштырганда, киңлеге буенча иң зур сак зоналарын (минималь рөхсәт ителә торган аралар зоналарын) таләп итә торган һәм әлеге участокта башка инженерлык коммуникацияләренә караганда өстенлеккә ия булган өстенлекле инженерлык коммуникацияләрен куллануга

нигезләнергә кирәк.

5.3.2.13. Булган территорияләрне саклау һәм комплекслы төзекләндерү зоналарында һәм төзелгән шәхси (бер фатирлы) һәм аз катлы төзелеш территорияләрен комплекслы үзгәртеп кору зоналарында, урам-юл челтәре чикләрендә челтәрләр салу мөмкинлеге булмаганда, инженерлык коммуникацияләре, хуҗаларының ризалыгы булганда, фатир яны кишәрлекләре территориясендә салына.

5.3.3. Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру үзенчәлекләре

Капиталь төзелеш объектларын проектлау кысаларында инженерлык инфраструктурасы корылмаларын урнаштыру Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә алып барылырга тиеш.

Булган төзелешкә хезмәт күрсәтү өчен инженерлык инфраструктурасы корылмаларын урнаштырганда:

- инженерлык инфраструктурасының аерым корылмалары транзит транспорт һәм төп җәяүлеләр коммуникацияләреннән турыдан-туры күренә торган зонадан тыш рөхсәт ителә. Инженерлык челтәрләренең техник коридорларыннан тыш объектның периметры буенча биек кәүсәле яшел үсентеләрдән һәм/яисә куаклардан торган полоса булдыруны күз алдында тотарга киңәш ителә;

- объектларны урнаштыруны территорияне планлаштыру буенча расланган проектлар нигезендә күз алдында тотарга кирәк;

- саклау һәм санитар-сак зоналарын исәпкә алырга кирәк;

- объектка хезмәт күрсәтү өчен аңа тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә кирәк;

- тикшерү нәтиҗәләре буенча киселергә тиешле агачлардан тыш, биек кәүсәле яшел үсентеләрне мөмкин кадәр күбрәк саклауны күздә тотарга кирәк.

Инженерлык инфраструктурасы корылмаларын урнаштыру рөхсәт ителми:

- урам киселешләрендә (койма урнаштыруны таләп итми торган җир асты объектларыннан тыш), тротуарларда;

- территорияләрдән югары интенсивлыкта файдалана торган территорияләр һәм Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә билгеләнгән, шәһәр төзелеше ягыннан әһәмиятле территорияләрдә аерым торучы (койма урнаштыруны таләп итми торган җир асты объектларыннан тыш).

Инженерлык инфраструктурасының аерым торучы объектларын табигать-

рекреация зоналары территорияләрендә, паркларда, скверларда, бульварларда урнаштырганда, аларны транзит транспорт һәм җәяүлеләр коммуникацияләреннән турыдан-туры күренә торган зоналардан читтә урнаштыру рөхсәт ителә. Объектның периметры буенча биек кәүсәле яшел үсентеләрдән һәм/яисә куаклардан торган полоса булдыруны күз алдында тотарга киңәш ителә.

5.3.4. Казан шәһәр округы халкының һәм территориясенең инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителә торган исәпләү күрсәткечләре һәм җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителеш күрсәткечләре

Халыкны һәм территорияне инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итүнең рөхсәт ителә торган минималь дәрәҗәсе түбәндәге күрсәткечләрдә чагыла:

а) ресурсларны сак тоту буенча планлаштырыла торган чараларны, шәһәрдәге һәм җир өсте агынты суларын агызу күләмнәрен, элемтә корылмалары сыйдырышлылыгын исәпкә алып, инженерлык ресурсларын куллану күләмнәрен билгеләү өчен файдаланыла торган исәпләү күрсәткечләрендә;

б) куркынычсызлык, ышанычлылык, энергетика нәтиҗәлелеге буенча билгеләнгән таләпләрне, табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны, әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә тискәре йогынтыны киметүне исәпкә алып, капиталь төзелеш объектларын төзүгә ихтыяҗлар нигезендә су белән тәэмин итү һәм су чыгару, электр, газ, җылылык белән тәэмин итү, элемтә өлкәсендә тәэмин ителә торган ресурсларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуны һәм Казан шәһәр округын баланслы перспективалы үстерүне тәэмин итә торган инженерлык инфраструктурасы объектлары типларында һәм төрләрендә;

в) кагыйдәләр җыелмасы, санитария кагыйдәләре һәм нормалары һ. б. нигезендә билгеләнгән саклау һәм санитар-сак зоналарын исәпкә алып, инженерлык инфраструктурасының гамәлдәге объектларын реконструкцияләү (капиталь ремонтлау) һәм яңаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләренең зурлыгында.

5.3.4.1. Казан шәһәр округы халкының һәм территориясенең инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешен билгеләү өчен исәпләнгән күрсәткечләрне формалаштыруның гомуми принциплары

5.3.4.1.1. Федераль әһәмияттәге инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы һәм параметрлары Россия Федерациясенең

энергетика өлкәсендә һәм федераль транспорт өлкәсендә (магистраль торба үткәргеч транспорты өлешендә) территориаль планлаштыру схемалары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарының хокукый актлары белән расланган федераль әһәмияттәге инженерлык инфраструктурасы объектларын үстерү һәм урнаштыру тармак схемалары һәм программалары белән билгеләнә.

5.3.4.1.2. Төбәк (республика) әһәмиятендәге инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы һәм параметрлары Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм республика башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарының хокукый актлары белән расланган республика күләмендәге тармак схемалары һәм программалары белән билгеләнә.

5.3.4.1.3. Җирле әһәмияттәге инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы һәм параметрлары Казан шәһәр округының Генераль планы, шәһәр тармак схемалары һәм программалары, Казан шәһәр округы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарының хокукый актлары белән расланган коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасы белән билгеләнә.

5.3.4.1.4. Район әһәмиятендәге инженерлык инфраструктурасы объектларына һәм расланган схемаларга һәм программаларга кертелмәгән локаль объектларга ихтыяҗны билгеләү, инженерлык инфраструктурасы системаларының һәркайсының гамәлдәге торышыннан, санитария, шәһәр төзелеше һәм экология чикләүләрен исәпкә алып, кулланучыларны таләп ителгән күләмдә тәэмин итү кирәклегеннән һәм тиешле параметрлардан чыгып, шәһәр төзелешен проектлау документларын эшләгәндә гамәлгә ашырыла.

5.3.4.1.5. Инженерлык ягыннан тәэмин итү системалары, энергетика нәтиҗәлелеге, әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә тискәре йогынтыны киметү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару, җылылык, электр, газ белән тәэмин итү, мәгълүмат һәм элемтә өлкәләрендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү буенча билгеләнгән таләпләр нигезендә, тулаем алганда Казан шәһәр округы территориясен һәм аның аерым өлешләрен хисап чорына балансланган перспективалы үстерүне тәэмин итүче, инженерлык инфраструктурасын барлыкка китерүче бердәм комплекс тәшкил итәргә тиеш.

Инженерлык инфраструктурасы территорияне гамәлдәге һәм перспективалы план буенча оештыруга, урам-юл челтәре, табигый шартлар (рельеф, яшел утыртмалар), инженерлык-геологик шартлар, актив шәһәр төзелешен үстерү зоналарын («үсеш нокталарын») урнаштыру белән бәйле

булырга тиеш.

Инженерлык инфраструктурасын үстерү схемасын сайлау, кайсы ведомствога каравына бәйсез рәвештә, инженерлык тәэмин итү системаларын техник-икътисади нигезләүгә һәм максималь координацияләүгә нигезләнергә тиеш.

Казан шәһәр округы территориясендә инженерлык коммуникацияләрен урнаштыру һәм төзү Казан шәһәр округы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы карары буенча гамәлгә ашырылырга тиеш.

5.3.4.1.6. Казан шәһәр округының тормышны тәэмин итү системаларына караган инженерлык инфраструктурасы системаларын үстерү тулаем барлык системаларның һәм аларның аерым элементларының өзеклексезлеген тәэмин итү һәм ышанычлы эшләвен арттыру, тыныч тормыштагы һәм хәрби характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларны гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен куллану мөмкинлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш:

а) тормышны тәэмин итү системасы объектларын, шул исәптән инженерлык инфраструктурасы объектларын энергия һәм су белән тәэмин итүнең автоном чыганаклары белән тәэмин итү;

б) төп корылмаларның җитештерүчәнлегенең һәм инженерлык инфраструктурасының линия объектларының үткәрү сәләтенең норматив резервын булдыру;

в) Столбище урынында барлыкка килгән җир асты сулары базасында су белән тәэмин итүнең резерв чыганагын тәэмин итү;

г) эчә торган суны һәм агып төшүче суларны чистартуның заманча куркынычсыз технологияләрен кертү;

д) инженерлык ягыннан тәэмин итү системаларының боҗра схемаларын булдыру, аларны ике һәм аннан да күбрәк чыганакларга тоташтыру;

е) су үткәрү челтәрләрендә, шул исәптән барлык һәм яңа шәхси төзелеш зоналарында, янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру;

ж) тормышны тәэмин итү объектларын, шул исәптән инженерлык инфраструктурасы объектларын электр тапшыруның кабель линияләре буенча электр белән тәэмин итү;

з) су китерә торган челтәрләрдә грунт юылуга һәм җимерелүләр барлыкка килүгә, коммуникацияләрдә янгыннар һәм шартлаулар, нефть һәм нефть продуктларын агызу белән бәйле аварияләр барлыкка килүгә китерә торган агып чыгу ихтималын киметү максатыннан, инженерлык инфраструктурасының линия объектларын вакытында реконструкцияләү яки капиталь ремонтлау, шул исәптән заманча траншеясыз ысуллар кулланып һәм полиэтилен торбалар

кулланып;

и) шәһәрнең шактый территорияләрен Куйбышев сусаклагычыннан су басуны һәм аларга су керүне булдырмау максатыннан гидротехник корылмаларны (дамбаларны, плотиналарны һәм дренаж системасын) капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү;

к) җирлекнең уңайсыз кишәрлекләрендә һәм потенциаль табигый һәм техноген һәлакәтләр зоналарында яңа объектлар яисә инженерлык инфраструктурасы объекты элементлары урнаштыруны, булганнарын реконструкцияләүне (киңәйтүне) булдырмау (чикләү);

л) инженерлык инфраструктурасы объектларын автоматлаштырылган контроль һәм дистанцион мониторинг системалары белән җиһазлау;

м) территорияләрне һәм бүлмәләрне авария очрагында яктыртуны тәэмин итү;

н) гражданнар оборонасын хәбәр итүнең локаль һәм берләштерелгән системаларын һәм Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм нәтиҗәләрен юк итүнең бердәм дәүләт системасын булдыру.

5.3.4.1.7. Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру 2.2.1/2.1.1.1200-03 номерлы санитария кагыйдәләре һәм нормалары белән күләмнәре гамәлгә кертелгән билгеләнгән санитар-сак зоналарын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Санитар-сак зонасы зурлыкларын киметү объектның тирә-юнь мохиткә һәм халык сәламәтлегенә барлык техноген тәэсир төрләрен кыскартуга юнәлдерелгән заманча техник һәм технологик чишелешләрен кертү шарты белән рөхсәт ителә. Санитар-сак зоналарын киметү проектын Казан шәһәр округы идарәсе органнары белән «Татарстан Республикасының гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән билгеләнгән тәртиптә килештерү зарур.

5.3.4.1.8. Барлык яңа, реконструкцияләнә торган, профилен үзгәрткән һәм киңәйтелә торган капиталь төзелеш объектлары перспективалы үсеш өчен үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, шәһәр агынтыларын һәм җир өсте суларын агызу, электр белән тәэмин итү, элемтә (телефон элемтәсе, радиотапшырулар, телевидение тапшырулары, янгын сүндерү һәм саклау сигнализациясе, диспетчерлык контроле) системалары белән тәэмин ителергә тиеш.

5.3.4.1.9. Казан шәһәр округы территориясендә инженерлык ягыннан

тәэмин итүнең гомумшәһәр үзәкләштерелгән системасын өстенлекле үстерү каралган.

Нигезләгән очракта район әһәмиятендәге инженерлык ягыннан тәэмин итүнең яңа үзәкләштерелгән системаларын һәм, төзелеш районнары яисә аерым объектлар гомумшәһәр үзәкләштерелгән системаларыннан шактый ерак булганда, локаль системаларны булдыру һәм булганнарының гамәлдә булу зонасын киңәйтү рөхсәт ителә.

Шәхси торак төзелеше, бакчачылык берләшмәләре территорияләрендә инженерлык коммуникацияләре төзү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә планлаштыру структурасы расланганнан соң гына рөхсәт ителә.

5.3.4.1.10. Барлык төзелгән территория, урам-юл челтәрен дә кертеп, җир өсте агынтысын җыю, чыгару һәм чистарту системасы белән тәэмин ителергә тиеш.

Сәнәгать предприятиеләре, склад хуҗалыклары, автохуҗалыклар һ.б. территорияләрдән, шулай ук торак төзелеше территорияләрендә урнашкан аеруча пычранган кишәрлекләрдән (органик һәм органик булмаган токсик матдәләр белән пычранган) агып төшкән сулар, чистартылган суларны җитештерү ихтыяҗлары өчен өстенлекле файдаланып, мөстәкыйль чистарту корылмаларында чистартылырга тиеш.

Табигатьнең яшелләндерелгән территорияләреннән (шәһәр урман паркларыннан) җир өстендәге суны, табигатьне саклау буенча вәкаләтле оешмаларның һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең экологик нигезләмәсе һәм мәгълүматы шартларында, Казан шәһәр округының эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганагына чыгарулардан тыш, чистартмыйча сулыкларга агызырга рөхсәт ителә.

5.3.4.1.11. Шәһәр территорияләреннән (сәнәгать предприятиеләре, төзелеш мәйданчыклары, оешмалар, учреждениеләр территорияләреннән) җир өстендәге суны (яңгыр һәм кар), су сибү-юу, дренаж агынтыларын, шулай ук норматив чиста, норматив чистартылган җитештерү барышында агып төшүче суларны шәһәрнең су агызу системасына кабул итү, җибәрү һәм чистарту Казан шәһәр округы башкарма хакимияте органнары тарафыннан расланган Казан шәһәренең агынты һәм (яки) дренаж суларын агызуның су чыгару системасыннан файдалану кагыйдәләре нигезендә башкарылырга тиеш.

Гамәлдәге тыгыз төзелгән шәһәр территорияләре шартларында җир өсте агымын җыюны һәм чистартуны оештыру мөмкинлеге булмаганда, аерым

территорияләрдән җир өсте агынты суларын, «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе техник шартлары буенча техник мөмкинлек булганда, шәһәрнең агынты сулар системасына (хуҗалык-көнкүреш канализациясе) кабул итү рөхсәт ителә.

5.3.4.1.12. Җылылык, электр һәм газ белән тәэмин итү системасы, Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексы үсеше белән бәйләп, Казан шәһәр округын энергия белән тәэмин итүнең комплекслы схемасының өлеше буларак проектлашырга тиеш.

5.3.4.1.13. Казан шәһәр округы энергия белән тәэмин итү системасын үстерү җылылык һәм электр энергиясен катнаш эшләп чыгаруны арттыруга юнәлдерелергә тиеш.

5.3.4.1.14. Яңа, реконструкцияләнә торган, профиле үзгәрә торган һәм киңәйтелә торган объектларны (шәхси һәм аз катлы торак төзелешләреннән һәм җитештерү шартлары буенча җылылык белән тәэмин итүнең махсус режимнары таләп ителә торган җитештерү-коммуналь билгеләнештәге объектлардан тыш) җылылык белән тәэмин итүне, җылылык белән тәэмин итүнең һәм җылылык энергиясен куллануның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген булдыруны исәпкә алып, күбесенчә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырып башкарырга кирәк.

Гамәлдәге җылылык чыганакларын нәтиҗәле җылылык белән тәэмин итү радиуслары чикләрендә автоном җылылык энергиясе чыганакларын төзү яки үзәкләштерелмәгән җылылык белән тәэмин итү турындагы карар җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлдәге җылылык чыганакларын үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системасы исәбеннән кулланучыларның җылылык энергиясенә ихтыяҗын канәгатьләндерүне техник-икътисади нигезләү шарты белән генә кабул ителергә мөмкин.

5.3.4.1.15. Шәхси (бер фатирлы) яки аз катлы торак төзелешен җылылык белән тәэмин итүне үзәкләштерелмәгән (фатир эчендәге автоном типтагы җылылык генераторларыннан) итеп тә, үзәкләштерелгән (гамәлдәге яки яңа котельныйлардан) итеп тә карарга мөмкин. Электр энергиясен җылыту һәм эчелә торган су белән тәэмин итү өчен куллану каралмый.

5.3.4.1.16. Яңа төзелештә һәм күпфатирлы торак йортларны һәм иҗтимагый биналарны җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташтыру узелларын реконструкцияләгәндә, автоматлаштырылган шәхси җылылык пунктларын кертүне күз алдында тотарга кирәк.

5.3.4.1.17. Шәһәр электр челтәрләрен проектлау барлык кулланучыларны

исәпкә алып комплекслы булырга һәм 110 кВ һәм аннан югарырак челтәрләрне 0,4 кВ, 6 кВ, 10 кВ һәм 20 кВ челтәрләре белән бәйләп башкарылырга тиеш.

5.3.4.1.18. Шәһәрне электр белән тәэмин итү системасының көчәнеше энергияне трансформацияләү баскычларының иң аз санын исәпкә алып сайланырга тиеш.

5.3.4.1.19. Газлаштырылган күпфатирлы торак төзелешенә газ бирү саклана.

Яңа күпфатирлы югары һәм урта катлы торак йортларны газ белән тәэмин итү, кагыйдә буларак, каралмый, моңа җирле үзидарәнең вәкаләтле органы карары буенча үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системаларыннан ерак урнашкан зоналарда урнаштырыла торган автоном җылылык чыганакларын газ белән тәэмин итү керми.

Шәхси (бер фатирлы) яки аз катлы торак йортларда табигый газ ризык әзерләү (торак йортны газ плитәләре белән җиһазландырган очракта), җылыту һәм кайнар су белән тәэмин итү өчен кулланыла. Шәхси (бер фатирлы) яки аз катлы торак йортларда ризык әзерләү өчен электр плитәләре кую рөхсәт ителә.

5.3.4.1.20. Казан шәһәр округы халкы тарафыннан салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүгә, су чыгаруга, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдалану нормативлары Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының хокукый актлары белән раслана.

Шәһәр төзелешен проектлау документларын эшләгәндә хуҗалык-эчү өчен ихтыяҗларга су чыгымнарының, җылылык һәм электр энергиясе, табигый газ, нефть продуктлары чыгымнарының, элемтә корылмалары сыйдырышлылыгының, шәһәрнең агып төшүче суларын агызу күләмнәренең әлеге нормативларда китерелгән исәпләү күрсәткечләре файдаланыла.

5.3.4.2. Хуҗалык-эчү өчен ихтыяҗларга су чыгымын билгеләү өчен кулланыла торган исәпләү күрсәткечләре

5.3.4.2.1. Хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен бирелә торган суның сыйфаты федераль законнар таләпләренә туры килергә тиеш.

5.3.4.2.2. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләгәндә хуҗалык-эчү ихтыяҗларына су куллану күләмен исәпләү 30.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы (А кушымтасы) һәм 31.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы (5 бүлек) нигезендә торак төзелеше районнарының төзекләндерү дәрәҗәсен һәм иҗтимагый һәм җитештерү-коммуналь билгеләнештәге объектларның төрләрен исәпкә алып башкарыла.

Гамәлдәге сәнәгать предприятиеләренең җитештерү ихтыяҗларына суның

исәпләнгән чыгымы, әлеге предприятиеләрнең үсеш (реконструкция) перспективаларын исәпкә алып, фактта үлчәүләр (аларны су белән тәэмин итүче оешмаларның хисап белешмәләре буенча яисә сәнәгать предприятиеләренең үз белешмәләре буенча) буенча; проектлана торган сәнәгать предприятиеләренең шундый ук җитештерү проектлары буенча яисә шушы предприятиеләрнең технологик белешмәләре нигезендә кабул ителә.

Гомуми файдаланудагы территорияләрдә, сәнәгать предприятиеләре территорияләрендә, аз катлы һәм шәхси торак төзелешендәге йорт яны кишәрлекләрендә урамнарга һәм яшел үсентеләргә сибү өчен эчәргә яраклы су чыгымы, территория өслеге төренә, аңа су сибү ысулына һәм үсентеләр төренә карап, 31.13330 кагыйдәләр җыелмасы (5.3 пункт) нигезендә кабул ителергә тиеш.

5.3.4.2.3. Янгын сүндерү өчен су чыгымнары 8.13130 номерлы кагыйдәләр җыелмасы һәм 10.13130 номерлы кагыйдәләр җыелмасы нигезендә кабул ителергә тиеш.

5.3.4.2.4. Суүткәргеч корылмаларының җитештерүчәнлеген һәм суүткәргеч челтәренең үткәрү сәләтен исәпләп чыгару өчен 31.13330 кагыйдәләр җыелмасы (5.2 пункт) нигезендә билгеләнә торган иң күп һәм иң аз су куллану буенча бер тәүлеккә исәпләнгән су чыгымнарын исәпкә алырга кирәк.

5.3.4.2.5. Шәһәр агынтыларының су чыгару күләмен билгеләү өчен кулланыла торган исәпләү күрсәткечләре.

5.3.4.2.6. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе системаларын проектлаштырганда, торак бинalardan агып төшүче көнкүреш суларын чыгаруның чагыштырмача уртача тәүлеклек (елына) исәпләнгән күләмен, территорияләргә һәм яшел үсентеләргә су сибүгә киткән суны исәпкә алмыйча, чагыштырмача уртача тәүлеклек (елына) исәпләнгән су куллануга тигез итеп кабул итәргә кирәк.

Шәһәрнең агынты сулары күләмнәрен исәпләү 32.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы (5 бүлек) нигезендә башкарыла.

5.3.4.2.7. Өслектәге агынты сулар күләмен билгеләү өчен кулланыла торган исәпләү күрсәткечләре.

Территорияне планлаштыру документларын эшләгәндә, өслектәге агынты сулар күләмен исәпләү 32.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы (7.2 бүлек) нигезендә башкарыла.

5.3.4.3. Җылылык йөкләмәсен билгеләү өчен кулланыла торган исәпләү күрсәткечләре

5.3.4.3.1. Җылылык белән тәэмин итү системасы объектларын

проектлаштыру өчен төп исәпләү күрсәткече булып җылылык, вентиляция һәм кайнар су белән тәэмин итүгә җылылык йөкләнешен үз эченә алган исәпләнгән гомуми җылылык йөкләнеше тора.

5.3.4.3.2. Территорияне планлаштыру документларын әзерләгәндә яңа һәм реконструкцияләнә торган торак һәм иҗтимагый биналарны җылытуга, вентиляцияләүгә һәм кайнар су белән тәэмин итүгә максималь җылылык йөкләнешен исәпләү 124.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы һәм 50.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасы нигезендә башкарыла.

5.3.4.3.3. Гамәлдәге сәнәгать предприятиеләренең исәпләнгән эреләндерелгән җылылык йөкләнеше, әлеге предприятиеләрнең үсеш (реконструкция) перспективаларын исәпкә алып, фактта үлчәүләр (җылылык белән тәэмин итүче оешмалар белешмәләре яисә сәнәгать предприятиеләренең үз белешмәләре) буенча; проектлана торган сәнәгать предприятиеләренең – төп (профильле) җитештерүне үстерүнең эреләндерелгән нормалары буенча, шундый ук җитештерү проектлары буенча яисә шушы предприятиеләрнең технологик белешмәләре нигезендә кабул ителә.

5.3.4.4. Табигый газга булган ихтыяҗны билгеләү өчен кулланылган исәп күрсәткечләре

5.3.4.4.1. Территорияне планлаштыру документларын эшләгәндә, газ белән тәэмин итү системасы объектларының техник параметрларын билгеләүче максималь сәгатьлек газ чыгымын гына исәпләү рөхсәт ителә.

5.3.4.4.2. Хуҗалык-көнкүреш ихтыяҗларына һәм сәнәгатьнең төрле тармакларына караган предприятиеләр һәм җитештерү характерындагы көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре өчен газның сәгатьлек һәм еллык максималь чыгымын исәпләү 42-101-2003 номерлы кагыйдәләр җыелмасы (3.9 - 3.20 пунктлар) нигезендә башкарыла.

5.3.4.5. Элемтә корылмаларына ихтыяҗны билгеләү

5.3.4.5.1. Телефоннарның, радионокталарның таләп ителә торган саны, элемтә челтәренең сыйдырышлылыгы, халыкка кабельле телевидение челтәрләре буенча мультимедиа хезмәтләрен күрсәтүне арттыруны исәпкә алып, спутник һәм кабельле телевидение системалары белән халыкны тәэмин итү проценты халык санына һәм эшләүчеләр санына бәйле рәвештә билгеләнә.

Элемтә челтәренең тыгызлыгы төрле категориядәге кулланучыларның элемтә хезмәтләренә ихтыяҗын канәгатьләндерү дәрәҗәсен күрсәтә торган рациональ нормалардан чыгып билгеләнә.

5.3.4.5.2. РД 45.120-2000 технологик проектлау нормалары һәм 2003 елның 7 июнендәге 126-ФЗ номерлы «Элемтә турында»гы федераль закон нигезендә,

территорияне планлаштыру документларын эшләгәндә, халыкны барлык төр электр элемтәләре белән 100% тәэмин итә торган нормативлар кулланыла.

5.3.4.6. Инженерлык инфраструктурасы корылмаларын урнаштыру өчен территория резервлау

5.3.4.6.1. Казан шәһәр округы халкын һәм территориясен инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итү максатыннан шәһәр төзелешен проектлау документларында шәһәрнең су белән тәэмин итү, агынты, өслектәге һәм дренаж суларын чыгару, электр, газ, җылылык белән тәэмин итү, элемтә системалары корылмаларын урнаштыру өчен территорияләрне резервлау зарур.

5.3.4.6.2. Инженерлык инфраструктурасы корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау Казан шәһәр округының Генераль планы һәм (яисә) территорияне планлаштыру документлары (булган очракта) нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналарында, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен федераль законнар нигезендә кирәкле башка территорияләр чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5.3.4.6.3. Су белән тәэмин итү системасы корылмаларын урнаштыру өчен территория резервлау.

5.3.4.6.3.1. Казан шәһәр округы халкын һәм территориясен эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү максатыннан эчәргә яраклы суны әзерләү һәм саклау өчен суүткәргеч корылмалар – су әзерләү станцияләре, җир өстеннән һәм җир астыннан су алу узеллары, су бирүне җайга салу узеллары урнаштыру күздә тотыла.

5.3.4.6.3.2. Су белән тәэмин итү системасының куркынычсызлыгын булдыру һәм эчәргә яраклы суның таләп ителә торган сыйфатын тәэмин итү максатыннан, эчә торган суны әзерләү һәм саклау өчен булдырылган, суны җир өсте һәм җир асты чыганакларыннан бирә торган барлык корылмаларда, кайсы ведомствоныкы булуга карамастан, өч пояс составында санитар сак зоналары оештырыла.

Эчү өчен билгеләнгән су белән тәэмин итү чыганакларының һәм су үткәргеч корылмаларның санитар сак зоналарын оештыруга һәм алардан файдалануга карата санитария-эпидемиология таләпләре 2.1.4.1110-02 номерлы санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә билгеләнә.

5.3.4.6.3.3. Су әзерләү станцияләре өчен җир кишәрлекләре зурлыклары корылмаларның егәрлегенә бәйле рәвештә, әмма 5.3.4.1 таблицасында бирелгән күрсәткечләрдән артмаган күләмдә кабул ителә.

5.3.4.1 таблица

**Эчәргә яраклы суны чистарту станцияләре урнашкан җир кишәрлекләренең (санитар сак зонасының I поясы) якынча зурлыклары**

| Корылмаларның егәрлеге, мең куб.м/тәүлек | Кишәрлекнең максималь зурлыгы, га |
|---|---|
| 0,8 гә кадәр | 1,0 |
| 0,8 дән 12 гә кадәр | 2,0 |
| 12 дән 32 гә кадәр | 3,0 |
| 32 дән 80 гә кадәр | 4,0 |
| 80 нән 125 кә кадәр | 6,0 |
| 125 тән 250 гә кадәр | 12,0 |
| 250 дән 400 гә кадәр | 18,0 |
| 400 дән 800 гә кадәр | 24,0 |

5.3.4.6.3.4. Су белән тәэмин итү системасының башка корылмаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләре зурлыклары, егәрлектән, технологик схемадан, урнаштырылачак җиһаздан һәм башка исәп параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндә билгеләнә.

5.3.4.6.4. Шәһәрдәге агынты суларны чыгару системасы корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау.

5.3.4.6.4.1. Агынты сулар утырмаларын эшкәртү корылмалары, кагыйдә буларак, чистарту корылмасы кишәрлеге чикләрендә яки депонирлау корылмасы кишәрлеге чикләрендә урнаша.

5.3.4.6.4.2. Агынты сулар утырмаларын, аларга сәнәгать эшкәртүе башкарылганнан соң, депонирлау корылмаларын урнаштыру өчен кишәрлек шәһәр чиге читендә урнашырга тиеш.

5.3.4.6.4.3. Янәшәдәге территорияләрне капиталь төзелеш өчен үзләштерә башлаганчы корылмалар биләгән кишәрлекне тулысынча формалаштыру, тутыру һәм консервацияләү, шулай ук корылманы гомуми файдаланудагы территорияләрдән су яисә башка киртә белән изоляцияләүне тәэмин итү шарты белән, шәһәр чикләрендә агынты сулар утырмаларын депонирлауның гамәлдәге корылмаларыннан файдалану рөхсәт ителә.

5.3.4.6.4.4. Агынты сулар утырмаларын депонирлау корылмаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлегенең зурлыгы җирле гидрогеологик, климатик, табигый факторларга, территория мөмкинлекләренә бәйле рәвештә һәм һәрбер конкрет очракта техник-икътисади параметрлар (ераклык, барып җитү мөмкинлеге һ.б.) исәпкә алынып билгеләнә.

5.3.4.6.4.5. Шәһәр төзелеше ягыннан проектлаштыруда су чыгару

системасы корылмаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләре зурлыклары 5.3.4.2 таблица буенча билгеләнә.

5.3.4.2 таблица

**Чистару корылмаларын һәм канализация насос станцияләрен урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең якынча зурлыклары**

| Корылмаларның җитештерүчәнлеге, мең куб. м/тәүлек | Җир кишәрлеге зурлыгы, га | |
|---|---|---|
| | чистарту корылмасы | канализация-насос станциясе |
| 0,2 гә кадәр | - | 0,0005 |
| 0,2 дән 5,0 гә кадәр | 1,0-1,5 | 0,001-0,1 |
| 5,0 дән 50,0 гә кадәр | 2,0-4,0 | 0,1-0,2 |
| 50,0 дән 100,0 гә кадәр | 4,0-6,0 | 0,2-0,5 |
| 100,0 дән 200,0 гә кадәр | 6,0-12,0 | 0,5-0,7 |
| 200,0 дән артык | Исәпләү буенча | 1,0-2,0 |

5.3.4.6.4.6. Шәһәр агынты суларын чыгару системасының башка корылмаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләре зурлыклары, егәрлектән, технологик схемадан, урнаштырыла торган җиһаздан һәм башка исәп параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндә билгеләнә.

5.3.4.6.5. Өслектәге һәм дренаж агынты суларын чыгару системасы корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау.

5.3.4.6.5.1. Өслектәге агынты суларны чистару корылмаларына ихтыяҗ түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

а) шәһәрнең барлык төзелгән территориясен чистару корылмалары белән тәэмин итү;

б) су агызу коллекторларыннан су объектларына чыгару урыннарында локаль яки төркемле чистару корылмаларын урнаштыру;

в) экологик яктан куркыныч булган мәйданчыкларны һәм объектларны урнаштыру, аларда локаль чистару корылмаларын төзү;

г) өслектәге һәм шартлы рәвештә чиста саналган җитештерү агынтыларын бергә чистарту өчен төркемле чистарту корылмаларын төзү (кирәк булганда).

5.3.4.6.5.2. Торак, иҗтимагый-эшлекле һәм җитештерү-коммуналь билгеләнештәге объектларны булган төзелеш зоналарында (булган кварталларда, микрорайоннарда, районнарда, сәнәгать зоналарында) шәһәр чистарту корылмалары булмаган урында урнаштырганда, яңа төзелеш участоклары территориясендә локаль чистарту корылмалары төзүне

планлаштырырга кирәк.

Локаль чистару корылмасыннан өслектәге чистартылган агынты суларны турыдан-туры су объектларына агызу мөмкинлеге булганда, локаль чистару корылмасында чистарту дәрәҗәсе 2.1.3684 - 21 номерлы санитария кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә туры килергә тиеш, шул ук вакытта локаль чистару корылмалары 5.3.2.3.17-5.3.2.3.19 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры китереп урнаштырылырга тиеш. Мондый мөмкинлек булмаганда, локаль чистару корылмасыннан чистартылган агынты суларны 5.3.3.1.17 пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә шәһәрнең су чыгару челтәрләренә агызу күздә тотылырга тиеш.

5.3.4.6.5.3. Чистарту корылмаларын сулыкларга чыгарыр алдыннан яңгыр канализациясе коллекторларының тамак участокларына урнаштырырга кирәк. Барлыкка килгән төзелеш шартлары буенча болай урнаштыру мөмкин булмаган очракта, чистарту корылмалары яңгыр канализациясе коллекторы агымы буенча югарырак урнашырга тиеш. Бу очракта су җыю бассейны өлешеннән өстәге агым чистартылмыйча гына сулыкка агып төшә.

5.3.4.6.5.4. Чистару корылмалары тибын һәм корылмаларын (ачык яки ябык) сайлау аларның җитештерүчәнлегеннән, аларны урнаштыру өчен территория булуыннан, урын рельефыннан, грунт сулары дәрәҗәсеннән һәм башкалардан чыгып билгеләнә.

5.3.4.6.5.5. Су объектларына чыгарыла торган өслектәге агынты суларны чистару дәрәҗәсе 2.1.3684-21 номерлы санитария кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә туры килергә тиеш.

5.3.4.6.5.6. Өслектәге агынты суларны чистару корылмаларыннан норматив санитар-сак зонасы 2.2.1/2.1.1.1200-03. 5.3.3.10.5.7 номерлы санитария кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечләр, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән килештереп, санитар-сак зонасын киметү чараларын эшләгәндә һәм тормышка ашырганда киметелергә мөмкин.

5.3.4.6.5.7. Чистару корылмалары алдыннан өслектәге агынты суларны җайга салу корылмаларын булдыру чистарту корылмалары зурлыгын киметү максатыннан шактый зур су җыю мәйданнары өчен башкарыла. Булган декоратив буаларны җайга сала торган буалар итеп файдаланырга мөмкин.

5.3.4.6.5.8. Җайга салу корылмалары кишәрлеге һәм санитар-сак зонасы зурлыгы проект документларын эшләгәндә билгеләнә.

5.3.4.6.6. Җылыту системасы корылмаларын урнаштыру өчен территория

резервлау.

5.3.4.6.6.1. Җылылык белән тәэмин итү системасы корылмаларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең мәйданнары, корылманың егәрлегеннән һәм технологик параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндәге исәпләүләр буенча билгеләнә.

5.3.4.6.6.2. Җылылык белән тәэмин итү системасының башка корылмаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләре зурлыклары, егәрлектән, технологик схемадан, урнаштырылачак җиһаздан һәм башка исәп параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндә билгеләнә.

5.3.4.6.6.3. Җылылык белән тәэмин итү чыганакларыннан санитар-сак зоналарының норматив зурлыклары 2.2.1/2.1.1.1200-03 номерлы санитария кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә туры килергә тиеш.

5.3.4.6.6.4. Санитар-сак зоналарын киметү чараларын эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда санитар-сак зонасының бирелгән зурлыклары Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе карары нигезендә киметелергә мөмкин.

5.3.4.6.7. Электр белән тәэмин итү системасы корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау.

5.3.4.6.7.1. Казан шәһәр округы халкын һәм территориясен тәэмин итү өчен электр белән тәэмин итү системасы объектларын: электр подстанцияләрен, җылылык һәм электр энергиясен бергә эшләп чыгару чыганакларын, электр тапшыру линияләрен, электр тапшыру һава линияләренең кабельле коллекторларга күчү пунктларын, кабельле коллекторлар, трансформатор подстанцияләренең бүлү пунктларын, тоташтыру пунктларын урнаштыру күздә тотыла.

5.3.4.6.7.2. Аерым тора торган ябык тукландыру үзәкләрен төзү өчен участок мәйданы түбәндәгечә булырга тиеш:

- 110 кВ – 0,2 - 0,5 га;
- 220 кВ – 1,2 - 1,8 га.

Электр белән тәэмин итү системасы корылмаларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең мәйданнары, корылманың егәрлегеннән һәм технологик параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндәге исәпләүләр буенча билгеләнә.

5.3.4.6.7.3. Электр белән тәэмин итү системасының башка корылмаларын урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләре зурлыклары, егәрлектән, технологик схемадан, урнаштырылачак җиһаздан һәм башка исәп

параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндә билгеләнә.

5.3.4.6.8. Газ белән тәэмин итү системасы корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау.

5.3.4.6.8.1. Казан шәһәр округы халкын һәм территориясен тәэмин итү өчен газ белән тәэмин итү системасы объектларын: газ бүлү пунктларын, газ чыгымын исәпкә алу узелларын, газны җайга салу пунктларын, газүткәргечләрне урнаштыру күздә тотыла.

5.3.4.6.8.2. Газ белән тәэмин итү системасы корылмаларын урнаштыру өчен җир кишәрлеге мәйданнары, корылманың егәрлегеннән һәм технологик параметрларыннан чыгып, проект документларын эшләгәндә исәпләүләр буенча билгеләнә.

Аерым торган шкафлы яки блоклы типтагы газны җайга салу пунктларын урнаштыру өчен җир кишәрлеге мәйданы объектның тибына һәм егәрлегенә бәйле рәвештә сайлана. Шкафлы газ көйләү пункты һәм блоклы газ көйләү пункты урнаштыру өчен җир кишәрлегенең минималь зурлыгы – 4 кв.м.

5.3.4.6.8.3. Аерым тора торган газ көйләү пунктыннан, блоклы газ көйләү пунктыннан һәм шкафлы газ көйләү пунктыннан биналарга һәм корылмаларга кадәр булган ераклыклар 5.3.4.3. таблицасында күрсәтелгәннән ким булмаска тиеш.

5.3.4.3 таблица

**Аерым тора торган газ көйләү пунктыннан, блоклы газ көйләү пунктыннан һәм шкафлы газ көйләү пунктыннан биналарга һәм корылмаларга кадәр ераклык**

| Газ көйләү пунктына керү урынында газүткәргечтәге газ басымы, МПа | Аерым торган газ көйләү пунктларыннан яктылыктагы ераклыклар (горизонталь буенча), м | | | |
|---|---|---|---|---|
| | биналарга һәм корылмаларга кадәр | тимер юл һәм трамвай юлларына кадәр (иң якын рельска кадәр) | автомобиль юлларына кадәр (юл читенә кадәр) | электр тапшыру һава линияләренә кадәр |
| 0,6 га кадәр | 10 | 10 | 5 | Кимендә багана биеклегеннән 1,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 0,6 дан алып 1,2 гә кадәр | 15 | 15 | 8 | Шулай ук |

Искәрмәләр:

1. Ераклык газ көйләү пункты, блоклы газ көйләү пункты һәм шкафлы газ көйләү пункты бинасының тышкы стеналарыннан, ә ачык мәйданчыкта җиһаз урнаштырылганда, койма читеннән алынырга тиеш.

2. Таблицадагы таләпләр шулай ук газ куллануны исәпкә алу узелларына һәм кран узелларына кагыла.

3. Тоташу урынында газның басымы 0,3 МПа га кадәр булганда, аерым тора торган шкафлы бүлү пунктыннан биналарга һәм корылмаларга кадәр ераклык нормага салынмый.

Тыгыз шартларда биналар һәм корылмалардан үткәрү сәләте 10000 куб.м/сәгатькә кадәр булган газ бүлү пунктына кадәрге ераклыкны 30 процентка киметү рөхсәт ителә.

Газ бүлү пунктыннан алып газ бүлү пунктлары кушып яки кертеп төзелә торган биналарга кадәр ераклык җайга салынмый.

5.3.4.6.9. Продукт үткәрү корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау.

5.3.4.6.9.1. Этиленүткәргечтәге булган компрессор станциясе саклана.

5.3.4.6.9.2. Этиленүткәргеч системасына кермәгән объектларны урнаштырганда, 36.13330 номерлы кагыйдәләр җыелмасының 7.16 пунктына туры китереп, компрессор станциясеннән коймадан алып минималь рөхсәт ителгән ераклыкны исәпкә алырга кирәк.

5.3.4.6.10. Элемтә корылмаларын урнаштыру өчен территорияне резервлау.

5.3.4.6.10.1. Элемтә системасы корылмаларын урнаштыру өчен җир кишәрлеге мәйданнары проект документларын эшләгәндә, корылманың егәрлеге һәм технологик параметрларыннан чыгып, исәпләү юлы белән билгеләнә.

5.3.4.6.10.2. Кабельле телевидениенең техник үзәкләрен махсус бүлмәләрдә яки торак йортның беренче катында, шулай ук күпкатлы торак һәм иҗтимагый биналарның югары техник катларында яки чормаларында урнаштырырга кирәк. Кабельле телевидениенең техник үзәкләре өчен аерым биналар һәм корылмалар төзү таләп ителми.

5.3.4.6.10.3. Җиһазны кимендә 12 кв.м мәйданлы, түшәм биеклеге кимендә 2,8 м булган, ясалма яктырту белән тәэмин ителгән бүлмәгә урнаштырырга кирәк. Бүлмә капиталь булырга, утка чыдамлылык буенча II дәрәҗәдән түбән булмаска, сак-янгын сигнализациясе һәм мәҗбүри һава суырта торган вентиляция белән җиһазландырылган булырга тиеш.

5.3.4.6.10.4. Башка элемтә объектларын урнаштыру өчен кирәк булган җир кишәрлекләре зурлыгы, егәрлектән, технологик схемадан, урнаштырылган җиһаздан һәм башка исәпләү параметрларыннан чыгып, проектны эшләгәндә билгеләнә.

5.3.4.7. Кар чистарту инфраструктурасы объектларының исәпләү күрсәткечләре

5.3.4.7.1. Казан шәһәр округы территориясеннән, шул исәптән урам-юл челтәреннән, ясалма транспорт корылмаларыннан (күперләр, эстакада, юлүткәргечләр һәм башкалар), йорт янындагы (ишегалдындагы) территорияләрдән, шәһәрнең башка территорияләреннән карны җыю, саклау һәм файдалану өчен, шул исәптән пычрак карны, карны чистарту инфраструктурасы объектларын күз алдында тотарга кирәк.

5.3.4.7.2. Кар чистарту инфраструктурасы объектларын Казан шәһәре Башкарма комитеты муниципаль хокукый акты белән расланган Казан шәһәр округы чикләрендә кар чистарту инфраструктурасы объектларын урнаштыру схемасы нигезендә проектлаштырырга кирәк.

5.3.4.7.3. Кар чистарту инфраструктурасы объектларының саны, аларның параметрлары һәм урнаштыру урыннары карны чистарту инфраструктурасы объектларын урнаштыру схемасенда түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

- чыгарылырга тиешле кар күләмнәре;

- карны чыгару эшләрен башкаруның оперативлыгын тәэмин итү (кар чыгаруда транспорт чыгымнарын минимальләштерү);

- канализация коллекторларының үткәрү сәләтләре һәм чистару корылмаларының егәрлекләре;

- чистару корылмаларына транспортның каршылыксыз үтә алуын тәэмин итү;

- кар чистартыла торган территорияләрнең якын урнашуы;

- агынты суларны агызу һәм кар суын чыгару нокталары булу;

- урам-юл челтәренә карата барып җитү мөмкинлеге;

- йөк автомобиль транспорты килеп җитү өчен уңайлылык һәм каршы якка хәрәкәтне оештыру;

- көчле кар яву чорларыннан соң чиратлар барлыкка килү мөмкинлеге;

- торак урыннарыннан ераклык;

- башка шартлар.

5.3.4.7.4. Территорияне планлаштыру документларын әзерләгәндә, кар чистарту объектлары кар чистарту инфраструктурасы объектларын урнаштыру буенча расланган схема нигезендә планлаштырыла. Әгәр кар чистарту

инфраструктурасы объектларын урнаштыруның расланган схемасы булмаса, территорияне планлаштыру документларын әзерләгәндә, кар чистарту инфраструктурасы объектларын түбәндәге очракларда планлаштырырга кирәк:

- территорияне планлаштыру документларында гомуми мәйданы 200 мең кв.метрдан артык булган торак төзелеш объектларын урнаштыру каралган булса;

- территорияне планлаштыру документларында гомуми мәйданы 100 мең кв.метрдан артык булган урам-юл челтәрен урнаштыру каралган булса;

- планлаштыру проекты территориясе чикләреннән 45 минут эчендә барып җитәрлек ераклыкта кар чистарту инфраструктурасының булган яки планлаштырылган объектлары булмаса.

Мондый планлаштыру документлары чикләрендә, әлеге җирле нормативларда билгеләнгән исәпләү күрсәткечләреннән чыгып, кар чистарту инфраструктурасы объектларын план буенча урнаштыру өчен зоналарны күздә тоту зарур.

5.3.4.7.5. Территорияне планлаштыру документларын әзерләгәндә, кар чистарту инфраструктурасы объектлары капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә инженерлык инфраструктурасы өлешендә урнаштырыла.

5.3.4.7.6. Кар чистарту инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешнең исәп күрсәткечләре.

5.3.4.7.6.1. Кар чистарту инфраструктурасы объектларын урнаштырырга рөхсәт ителми:

- су объектларының суны саклау зоналарында, боз катламы өслегендә һәм су объектының су җыю территориясендә;

- махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә;

- мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә;

- торак зоналар чикләрендә;

- территорияне планлаштыру документлар составындагы торак төзелеше өлешендәге капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру территорияләре чикләрендә;

- әлеге пунктта китерелгән территорияләр һәм зоналардан 50 м якынрак территорияләрдә. Ераклык кар чистарту инфраструктурасы объектының санитар-сак зонасы чикләре проекты белән киметелергә мөмкин.

5.3.4.7.6.2. I һәм II дәрәҗәле планлаштыру берәмлекләре өчен карны вакытлы саклау өчен мәйданчык күздә тоту зарур. Карны вакытлыча саклау мәйданчыгының җир кишәрлеге һәм (яки) планлаштырылган урнаштыру зонасы

мәйданы түбәндәгечә исәпләнә: 100 мең кв.м планлаштырылган урам-юл челтәре өчен 1,5 Га мәйданчык.

Карны вакытлыча саклау мәйданчыгында түбәндәгеләр булырга тиеш:

- каты өслек;

- барлык периметр буенча кар суларының рельефка эләгүеннән саклый торган валлар белән әйләндереп алу;

- су җыю лотоклары һәм кар суларын локаль чистару корылмаларына транспортировкалау системасы;

- барлык периметр буенча койма;

- контроль-үткәрү пункты.

Карны вакытлыча саклау мәйданчыгы территориясен җәй чорында автотранспорт куеп тору урыны (парковка) оештыру яки башка максатлар өчен кулланырга рөхсәт ителә.

5.3.4.7.6.3. Кар эретү станциясен җир кишәрлеге план буенча урнаштыру зонасы һәм (яки) мәйданы 100 мең кв.м урам-юл челтәренә хезмәт күрсәтү исәбеннән проектлаштырылган бер кар эретү камерасы өчен 0,5 Га исәбеннән кабул ителә.

Кар эретү шахталарында түбәндәгеләр булырга тиеш:

- кар эретү камерасы;

- буфер мәйданчыгы;

- чүпне вакытлыча саклау мәйданчыгы;

- автотранспортны, шул исәптән кар чистарту инфраструктурасы объектларына карны ташый торган йөк автотранспортын вакытлыча көтү мәйданчыгы;

- барлык периметр буенча койма;

- контроль-үткәрү пункты;

- бер катлы җитештерү-көнкүреш бинасы;

- һәр якка да ике полосалы хәрәкәтне тәэмин итүче шәһәр урам-юл челтәренә чыгу юлы.

Кар эретү шахталары корылмаларында барлык кыш чоры дәвамында бушаткан карны эретү, шулай ук норматив күрсәткечләренә кадәр эрү суларын чистарту каралырга тиеш. Кар эретү камерасы өслеге алына торган плитәләр белән капланган булырга тиеш.

Кар эретү шахталарын урнаштыру өчен кишәрлек кар суы кабул итү корылмасыннан 150 метрдан артык булмаган ераклыкта урнаштырырга кирәк.

Кар эретү камераларын урнаштырырга кирәк:

- аларга агынты су агызыла торган өслектән өстәрәк;

- байпаска агынты су чыгарыла торган каналларның урнашу биеклегендә.

Кар эретү пунктларын урам-юл челтәреннән җыелган карны һәм бозны эретү өчен агып төшүче суларның җылысын, алынган кар суын үзагышлы канализациягә агызып, файдалана торган канализация корылмаларында ясарга рөхсәт ителә.

5.3.4.7.7. Казан шәһәр округы халкы өчен кар чистарту инфраструктурасы объектларының территория ягыннан барып җитәрлек булуның максималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре.

Кар чистарту инфраструктурасы объектлары мондый инфраструктура объектларына транспортировкалау максатыннан кар чистарту башкарыла торган территорияләрдән 45 минуттан артык булмаган вакытта барып җитәрлек ераклыкта урнаштырылырга тиеш».

3. 6 «Исәпләү күрсәткечләрен нигезләү материаллары» бүлегендә:

3.1. 6.2 «Социаль инфраструктура объектларының исәпләү күрсәткечләрен нигезләү» бүлегендәге 6.2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6.2.4. Белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин ителүне исәпләү ысулы

6.2.4.1. Белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин ителү исәпләнә торган территориянең чикләрен билгеләү.

6.2.4.1.1. Исәпләнә торган планлаштыру районының чикләре гомумшәһәр әһәмиятендәге магистраль урамнар, тимер юл линияләре, су объектларының табигый чикләре һәм башка табигать территорияләре, торак пункт чикләре, Казан шәһәр округының Генераль планы белән билгеләнгән торак функциональ зоналары һәм торак төзелеш рөхсәт ителгән зоналар чикләре, магистраль яки технологик үткәргеч торбаларга (газүткәргечләр, нефть үткәргечләр һәм нефть продуктлары үткәргечләр, нефть һәм газны эшкәртү продуктларын үткәргеч торбалар, аммиак үткәргечләр) минималь ераклык зоналары – махсус куллану шартлары булган территория зоналары буенча билгеләнә.

6.2.4.1.2. Исәпләнә торган планлаштыру районы чикләренә шулай ук керә:

- торак булмаган функциональ зоналар чикләрендә урнашкан белем бирү оешмалары территорияләре;

- I һәм II дәрәҗә планлаштыру берәмлекләренең мөстәкыйль билгеләре булмаган, исәпләнә торган планлаштыру районы янәшәсендә урнашкан периферийдәге территорияләр.

6.2.4.1.3. Территорияләрдә булган һәм планлаштырыла торган торак төзелеше объектлары территорияне планлаштыру проекты чикләрендә гамәлдәге һәм планлаштырыла торган белем бирү оешмалары белән тәэмин ителгән

очракларда, территорияне планлаштыру буенча расланган документлар булган территорияләрне исәпләү башкарыла торган планлаштыру районы чикләренә кертмәү рөхсәт ителә.

6.2.4.2. Булган һәм планлаштырылган торак төзелеше күләмен билгеләү.

Исәпләү башкарыла торган планлаштыру районы чикләрендәге фатирларның гомуми мәйданы һәм (яки) йорт хуҗалыклары саны (аерым торак йортлар һәм блоклы төзелеш йортлары) исәбенә керә:

1) барлыкка килгән күпфатирлы торак йортлар:

- ачык чыганаклардан алынган мәгълүматлар буенча (Россия Федерациясенең Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасы);

- территорияне планлаштыру буенча расланган документларда күрсәтелгән мәгълүматлар буенча;

- булган блоклы һәм шәхси торак төзелеше өчен – Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры мәгълүматлары буенча җир кишәрлекләре саны буенча;

2) планлаштырыла торган торак йортлар түбәндәге мәгълүматлар буенча:

- төзелешкә рөхсәт;

- архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренеше, мондый объектларны төзүгә рөхсәт алынмаган очракларда, вәкаләтле орган тарафыннан килештерелгән проект документлары;

- мондый территорияләрдә планлаштырыла торган торак төзелеше объектлары территорияне планлаштыру проекты чикләрендә гамәлдәге һәм планлаштырыла торган белем бирү оешмалары белән тәэмин ителмәгән очракларда, территорияне планлаштыру буенча расланган документларда күрсәтелгән мәгълүматлар.

6.2.4.3. Булган һәм планлаштырыла торган белем бирү оешмаларын билгеләү.

6.2.4.3.1. Исәпләүгә Казан шәһәре Башкарма комитеты мәгълүматлары буенча булган белем бирү объектлары (саны һәм проект егәрлеге), шулай ук шәхси белем бирү оешмалары, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту өчен билгеләнгән белем бирү оешмаларыннан кала, федераль һәм төбәк белем бирү оешмалары кертелә.

6.2.4.3.2. Исәпләүгә планлаштырыла торган белем бирү оешмалары (саны һәм проект егәрлеге) түбәндәге мәгълүматлар буенча кертелә:

- төзелешкә рөхсәт;

- архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренеше, мондый объектларны төзүгә рөхсәт алынмаган очракларда, вәкаләтле орган тарафыннан килештерелгән проект документлары;

- белем бирү оешмасы Казан шәһәрендә мәгарифне үстерүгә юнәлдерелгән программага кертелгән, аны төзү өчен җир кишәрлеге төзелгән һәм (яисә) проект документлары эшләнгән, проект документларын әзерләү дәүләт (муниципаль) биремена кертелгән, аны әзерләү өчен дәүләт (муниципаль) контракты төзелгән очракларда, шулай ук аерым торган объектлар өчен территорияне планлаштыру буенча расланган документларда күрсәтелгән мәгълүматлар;

- территорияне комплекслы үстерү турында карар һәм (яки) территорияне комплекслы үстерү турында төзелгән килешү.

6.2.4.4. Яңа торак төзелеше объекты өчен белем бирү оешмаларында урын җитмәү (кытлык) булуын билгеләү.

Әлеге нормативларның 5.1.1.1.1 таблицасында бирелгән күрсәткечләр буенча планлаштыру элементы чикләрендә ачыкланган барлык торак өчен мәгариф оешмаларына гомуми ихтыяҗ исәпләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «2029 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәтләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында»гы карары белән билгеләнгән сменалылык коэффициентын кулланып, гамәлдәге мәгариф оешмаларындагы урыннарның гомуми санынннан мәгариф оешмаларындагы урыннарның гомуми ихтыяҗы төшереп калдырыла («а» күрсәткече – гомуми факттагы исәпләнә торган планлаштыру районы өчен мәгариф оешмаларында урыннар профициты).

«А» күрсәткече нульгә тигез яисә аннан азрак булганда, исәпләнә торган планлаштыру районы чикләрендә планлаштырыла торган торак төзелеше әлеге бүлек нигезендә белем бирү оешмалары белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар белән, шулай ук әлеге планлаштырыла торган торак төзелеше өчен эшләнә торган территорияне планлаштыру проектында, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү проектында, планлаштырыла торган торак төзелешенең проект документларында тәэмин ителергә тиеш.

Планлаштырыла торган торак төзелеше өчен планлаштырыла торган торак төзелешенең җир кишәрлеге чикләреннән әлеге нормативларның 5.1.1.1.1 таблицасында күрсәтелгән күрсәткечләр буенча исәпләнгән радиуска (алга таба – исәпләнгән радиус) тулысынча яки өлешчә керә торган исәпкә кертелергә тиешле белем бирү оешмалары ачыклана.

Исәпләнгән радиус чикләрендәге белем бирү оешмаларында урын җитмәүчәнлеге түбәндәге формула буенча һәр ачылган белем объекты өчен исәпләнә:

$$x = \frac{a \times b}{c}, \text{ биредә:}$$

x – белем бирү объектының йөкләнеше күрсәткече (урыннар);

a – исәпләнгән планлаштыру районы өчен белем бирү оешмаларында факт буенча урыннар җитмәүнең гомуми саны;

b – аерым бер белем бирү оешмасының проект буенча егәрлеге;

c – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «2029 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәтләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында»гы карары белән билгеләнгән сменалылык коэффициентын кулланып, гамәлдәге белем бирү оешмаларында һәм планлаштырыла торган белем бирү оешмаларында урыннарның гомуми саны.

Белем бирү оешмаларының исәпләнгән радиустагы йөкләнеш (урын) күрсәткечләре бергә кушыла, алынган нәтиҗәдән әлеге нормативларның 5.1.1.1.1 таблицасында күрсәтелгән күрсәткечләр буенча исәпләнгән планлаштырылган торак төзелеше өчен белем бирү оешмаларына ихтыяҗ алына. Йомгаклау күрсәткече нульгә тигез яисә аннан да күбрәк булганда планлаштырыла торган торак төзелеше мәгариф оешмаларында урыннар белән тәэмин ителгән була»;

3.2. 6.5 «Инженерлык инфраструктурасы объектларының исәпләү күрсәткечләрен нигезләү» бүлегендә:

3.2.1. 6.5.2 «Җирле нормативларның төп өлешендә булган исәпләү күрсәткечләрен нигезләү буенча методик нигезләмәләр» пунктының унынчы абзацында «информатика һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2.2. 6.5.3 «Казан шәһәр округы халкының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешенең рөхсәт ителә торган минималь дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләрен һәм мондый объектларның территориаль яктан файдалана алуының рөхсәт ителә торган максималь дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләрен нигезләү» пунктында:

3.2.2.1. дүртенче, җиденче, сигезенче абзацларда «информатика һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2.2.2. унынчы абзацта «зоналар» сүзләрен «коридорлар» сүзләренә алмаштырырга;

3.2.2.3. унберенче абзацта «техник» сүзеннән соң «коридорлар» сүзен өстәргә.

4. Казан шәһәр округын шәһәр төзелеше ягыннан прроектлаштыруның җирле нормативларына 1 номерлы кушымтада:

4.1. дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«**Үзгәртеп корыла торган территория** – сәнәгать, җитештерү, коммуналь-склад территорияләре, сәүдә-күргәзмә комплекслары, мәдәни мирас объектларын заманча файдалануга җайлаштыру белән бәйле территорияләр урынында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектлары белән тәэмин ителгән торак төзелешен гамәлгә ашыру максатыннан территориянең функциональ билгеләнеше үзгәрү шартларында территорияне үзгәртеп төзү, үзгәртеп оештыру, аннан адаптив файдалану, шулай ук гамәлдәге торак фондын реновацияләү чаралары комплексы, ягъни авария хәлендәге, тузган һәм, сакланырга тиеш булмаган башка торак йортларны сүтеп, яңа торак төзү»;

4.2. туксанынчы абзацта «**Техник коридор»** сүзләреннән соң «**(техник полоса)**» сүзләрен өстәргә**;**

4.3. түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«**Этләрне йөртү урыны –** иҗтимагый киңлектә бүлеп бирелгән, 0,7 метрдан биегрәк декоратив киртә белән әйләндереп алынган яисә куаклык белән зоналаштырылган, кыска вакытлы йөртү, гигиеник йөртү, тәрбияләү, социализация һәм эт белән уйнау өчен файдаланыла торган, эт белән йөрүне контрольдә тотуны күздә тоткан территория.

**Этләр өчен уен мәйданчыгы (уйнау, йөртү, этләрне социализацияләү һәм тәрбияләү өчен мәйданчык) –** этне муенчаксыз йөртү, этләрнең үзара аралашуы өчен билгеләнгән, кеше белән эт арасында эмоциональ бәйләнешне ныгыту максатыннан йөртү, тәрбияләү, социальләштерү һәм аларның уеннар аша аралашуы өчен файдаланыла торган, эт үтә алмаслык койма белән әйләндереп алынган һәркем файдалана алырлык территория.

**Дрессировка мәйданы –** этләргә аерым яки төркемдә күнекмәләр өйрәтү, кинологлар җитәкчелегендә этләр белән төрле спорт төрләре буенча шөгыльләнү, шулай ук кинологик чаралар үткәрү һәм мәгариф-агарту эшчәнлеге алып бару өчен билгеләнгән, койма белән әйләндереп алынган территория».

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**